

ОНЛАЙН ЯРМИНКӘ

Фермерлар интернет сәүдәгә кушылырга ашыкмый

> 5

СОҢГЫ БУРЫЧ

Түбән Камада Илнур Сибгатуллин белән хушлаштылар

> 15

КАМАЛ ТЕАТРЫ

Яңа бина турындагы төп сорауларга ачыклык кертәбез

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 31 (28804) | Җомга | 4 март | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

pixabay.com

КЕШЕГӘ... КЕШЕ КИРӘК!

АВЫР ЧАКТА КАЙДАН КӨЧ АЛЫРГА?

Һәркемнең күңеленә тәэсир итә торган вакыйгалар үзәгендә яшибез. Чынбарлыкның кичәгедән никадәр аерылуын, кемнең кем икәнен дә ачык күрсәтә торган вакыт. Бу куркыта. Һәм бу – куркыныч. Шулай да мондый шартларда да фикерләү, кичерү, ярату, аңлау, сабыр итү, анализлау сәләтенә ия булган зат – кеше булып каласы иде... «Ничек?» дигән сорауга җавапны бергәләп эзлибез.

> 6

Ишетми калмагыз

Паралимпиадага да кертмиләр

Халыкара паралимпия комитеты (IPC) Россия һәм Белоруссия спортчыларын 4–13 март көннәрендә Пекинда узарга тиешле Паралимпия уеннарына кертмәячәк. IPC әлеге хәлне «юкса күп илләрнең җыелма командалары Паралимпия уеннарында катнашудан баш тартачак» дип аңлаткан. Россия Паралимпия комитеты бу карарны «нигезсез, чөнки паралимпия хәрәкәтенең төп принципларыннан берсенә – инвалидлар спортының сәясәткә катылмау принцибына каршы килә» дип бәяләде. Моңа кадәр ике илнең паралимпиячеләренең Пекиндагы Уеннарда, IPC әләме белән, нейтраль статуста катнашачаклары турында хәбәр ителгән иде. Спортчыларның бүләкләрен медальләрнең рәсми булмаган исемлегенә кертмәү күздә тотылды.

Россия Президенты матбугат секретаре Дмитрий Песков IPC карары уңаеннан: «Коточкыч хәл. Халыкара паралимпия комитеты өчен хурлык бу. Әлбәттә, без әлеге карарны кискен гаеплибез», – диде. Җыелма командага Татарстаннан Рушан Минегулов һәм Марта Зәйнуллина кергән иде.

Ризык сыйфатын тикшергәннәр

Роспотребнадзор идарәсе хезмәткәрләре узган елда 39 муниципаль берәмлектәге кибетләрдә азык-төлекнең сыйфатын тикшергән. Барлыгы 264 ризыкка тикшерүнүләр уздырылган. Бу хакта ведомство башлыгы Марина Патяшина белдергән. Аның әйтүенчә, азык-төлек үрнәкләренең 21 процентының (һәр биш үрнәкнең берсе) билгеләнгән таләпләргә туры килмәве ачыкланган. Тикшерүләр вакытында балык сыйфатында кимчелекләр, катырылган балыктагы бозның продуктның үзенә караганда зуррак авырлыкта булуы беленгән. Шулай ук колбасага «ит җилеме» өстәүнең өч очрагы билгеләнгән. Патяшина әйтүенчә, мондый өстәмәне ризык составында күрсәтү мәҗбүри.

Юлчылар ташуга әзерләнә

Татарстанда су басу куркынычын булдырмауга әзерләнәләр. «Волго-Вятскуправодор» хезмәткәрләре язгы ташу чорында юлларның иминлеге өчен чаралар күрә. Сууткәргеч торбаларны кар-боздан чистарту башланган. 22 марттан юлчылар инҗенерләрдәге, елга-күлләр янәшәсеннән узучы юл өлешләрен тикшерә башлаячак. Туфракның судан юешу ихтималы булган урыннар аерым игътибар үзәгенә алыначак. Бу эшләргә 213 кеше җәлеп ителә.

Районнарда ни хәлләр?

Азнакай

Район башлыгы Марсель Шәйдуллин Азнакайда яшәүче Иргашевлар һәм Шәфыйковлар гаиләләренә торак шартларын яхшыртуга сертификатлар тапшырды. Район яшь гаиләләрне, яшь белгечләрне торак белән тәэмин итүдә күптөрле федераль һәм республика дәүләт программаларында актив катнашып килә. Узган ел 38 гаилә шундый программалар буенча социаль түләүләр һәм яңа йортлардан фатир алды. Быел да анда катнашырга теләк белдерүчеләр арта тора. «Барлык хыялларыгыз тормышка ашсын! Уңайлы, иркен йортларда сабыйларыгызны тигезлектә, исән-сау үстерегез!» – диде Марсель Шәйдуллин, гаиләләргә берәр миллион сумлык дәүләт ярдәме таныклыклары тапшырып.
(«Маяк»)

Кукмара

Мәчкәрә авылында XVII гасырда салынган борынгы тарихи мәчетне реставрацияләргә җыеналар. Әлеге гыйбадәтханә республика әһәмиятендәге архитектура һәйкәле булып исәпләнә. Мәчкәрә авылындагы Җәмигъ мәчете 1791 елда беренче гильдия сәүдәгәре Габдулла Үтәмешев акчасына төзелгән. Мәчет каршында мәдрәсә булган, анда төрле елларда Казан, Уфа һәм Нократ губерналарының күп кенә мөселман руханилары дини белем алган. Мәдрәсәдә укучылар арасында Габденнасыйр Курсави – күренекле акыл иясе һәм ислам реформаторы да бар.
(dumrt.ru)

Теләче

Узган ел районда сөткә бәя, алдагы ел белән чагыштырганда, җиде сумга артык булган. Теләче районы башлыгы Нәҗип Хаҗипов сүзләренә караганда, бер литр сөткә 27 сум түләгәннәр. 4275 шәхси ярдәмче хуҗалыкта 6717 баш мөгезле эре терлек, шул исәптән 2063 савым сыеры исәпләнә. «100 йортка 48 баш туры килә (республика буенча 25 баш). Һәр авылда 6 һәм аннан күбрәк сыер асраучы хуҗалыклар шактый. Барлык торак пунктларда да халыктан сөт җыела», – диде район башлыгы.
(«Татар-информ»)

Арча

Район үзәгендә «Запорожец» машиналарында узыштылар. Быел 12 нче тапкыр оештырылган узышларда Арча, Әтнә, Биектау, Азнакай, Лениногорск районнарыннан 30 машина йөртүче катнашты. Финал ярышы Лениногорск егетләренең быел да җитезрәк икәнен күрсәтте. Беренче урынны яулап, кучмә кубокка Лениногорск районыннан Валерий Васильев лаек булды. Икенче урында – аның якташы Айрат Исмәгыйлев, өченче урында – Урта Курсадан Динар Гарипов. Шулай ук гүзәл затларыбыз да «тимер ат»ларда көчләрен сынап карадылар. Әлеге ярышларда Кысна авылы кызы Айзилә Фәйзрахманова иң оста йөртүче һәм иң җитезе булып чыкты.
(«Арча-информ»)

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ:

«ЯШЬ ӘНИЛӘРНЕҢ ӨЙДӘ ГЕНӘ УТЫРУЫ ДӨРЕС ТҮГЕЛ»

tatarstan.ru

«Һәр хатын-кыз ике-өч бала тапсын иде». Халыкара хатын-кызлар көне уңаеннан Рөстәм Миңнеханов Казан Кремлендә массакүләм мәгълүмат чараларында эшләүче нәфис затлар белән очрашуда әнә шулай диде.

Чара күңелле мизгелләрдән башланып китте. Президент башта үз хезмәтләренә тугры булган, тырышып эшләүче туташ-ханымнарга дәүләт бүләкләре тапшырды.

– Без инде ике ел гади булмаган пандемия чорында яшибез. Күпләр яңа эш формалары тапты, кемнәрдер онлайнга күчте. Сез исә – үз эшегездә, аны җаваплы башкарасыз. Һөнәри осталыгызны күрәбез, бәялибез. Матур, акыллы, уңышлы булудан тыш, сез әле эшлекле дә, – дип, Президент матур сүзләрне бер дә жәлләмәде.

Тантана өлешеннән соң сөйләшү табын янында дәвам итте. Истә калырлык җылы бер очрашу булды ул. Әлбәттә, җиңел генә түгел, җитди сорауларга да урын бар иде. Чара алдыннан Яшел Үзәндәге логистик үзәккә пресс-тур оештырылды. Анда «Озон» үзәгендә маркетплейс хезмәтенең ничек тормышка ашырылуы белән таныштык. Белгечләр әйтүенчә, соңгы вакытта электрон сәүдә системасына теркәлүче эшмәкәр хатын-кызлар саны берничә тапкыр арткан. Соңгы вакытта, хатын-кызлар ирләре алдыннан чабарга ярата, дигән сүзләрне ешрак ишетә башладык бит. Кызык, Президент эшмәкәрләргә, шулай ук өйдә генә утыручы хатын-кызларга ничек карый икән?

– Хәзер шартлар икенче. Яшь әниләрнең өйдә генә утыруы дөрес түгел. Ял иткәндә дә күңелгә туры килгән шөгыль табарга була бит. Бала тудыру гына түгел, аны карарга да кирәк. Биләүсәдән төшүгә бакчага илтергә ашыкмасыннар, 3 яшькә кадәр сабыйларын үзләре тәрбияләсеннәр иде. Элек түгәрәкләр, спорт мәктәпләре юк иде, хәзер балалар шунда йөри, хатын-кызларга исә үзләрен үстерү өчен мөмкинлекләр күбрәк, – диде Президент.

Электрон сәүдә белән танышып кайтканнан соң, Президентның интернет кибеттән әйберләр сатып алуы-алмавы турында да беләсе килде. Гомумән, ул киемнәрне каян сатып ала икән?

– Мин маркетплейс хезмәтен кулланып карадым. Интернет кибет аша «толстовка»га заказ биргән идем. Бар да тәртиптә: акчасын да алдылар, киеме дә вакытында килде. Кибетләргә йөрергә яратмыйм. Болай кием-салымны хатыным сатып ала, ул үлчәмнәремне белә. Кайбер кибетләр ябыла, онлайн эшли башлый, чөнки маркетплейслар, офлайн кибетләр белән чагыштырганда, уңайлырак. Анда хезмәт күрсәтү сыйфаты күпкә югарырак. Бу – безнең киләчәк. Электрон сәүдә – үсештә. 2021 елда Татарстанда маркетплейсларга теркәлгән эшмәкәрләр саны 7 тапкыр арткан, – диде Президент.

Очрашуда Рөстәм Миңнеханов демография мәсьәләсе борчуын әйтте. Аның фикеренчә, әлеге вазгыять бүген бик кискен тора. Республикада 2010 елдан балалар тууы буенча уңай күрсәткеч күзәтелгән. Хәзер 2003 елдагы демография күрсәткеченә төшкәнбез. Моңа пандемиянең дә тәэсире бар.

– Элек һәр гаиләдә өчәр бала табу гадәткә әйләнгән иде. Шартлар башка булса да, балалар саны ким булмаган. Адәм баласы күбрәк яши башласа, күбрәк үзе турында уйлый, киләчәк өчен борчылмый. Баланы табу гына түгел, аны үстерәсе дә бар. Әлеге йөк хатын-кызлар җилкәсенә төшә, – диде Рөстәм Миңнеханов. Сүз уңаеннан, Президент Казанда тагын бер перинаталь үзәк төзелә башлавын да искәртеп узды. Хәзер төп максат – сабыйлар санын арттыру. Республика Президентының матбугат хезмәте җитәкчесе Лилия Галимова исә, үзәктә яшь әниләрне бизәндерү өчен аерым бүлмә дә булдырылачак, дип өстәде.

Президенттан, Камилә Вәлиеваның чыгышларын карадыгызмы, дип сораучылар да булды.

– Карадык. Камилә – беренче, ул дөньяда – иң яхшысы. Мәгълүмати һөҗүмгә каршы тора алды, аңа карата эшләнгән гамәлләр гадел түгел. Спорт сәясәткә бәйле булмаска тиеш. Ни генә әйтсәләр дә, ул безнең өчен иң әйбәте. Аның татар кызы булуы, Казанда тууы белән дә горурланабыз. Без аны чакырырбыз, очрашырбыз. Киләчәктә үзен күрсәтә алыр дип ышанам, – диде ул.

Шәһәр яннарында микрорайоннар төзелсә дә, анда яшәү өчен шартлар җитеп бетми. Бу очракта анда инфраструктураны кем хәл итәргә тиеш: республикамы, районнармы, төзеп бирүчеләрме? Бу хакта Президент ни уйлый?

– Без бу проблеманы бергәләп хәл итәргә тиеш. Аны районнар гына башкарып чыга алмый. Карар кабул иткәндә, йортларны төзеп бирүче компанияләр дә социаль үсешне үстерүдә катнашырга тиеш. Әйтик, йә бакча, йә сырхауханә төзүдә. Республика программалары да бар. Гомумән алганда, комплекслы төзү транспортны да, социаль үсеш белән тәэмин итүне дә күздә тота. Бу анда яшәүче халык өчен бик мөһим. Хәзерге вакытта торак төзелеше темплары микрорайоннардагы социаль үсеш булдыруга караганда алдарак бара. Бу – безнең эшләп бетермәгән як, акча мәсьәләсенә бәйле. 1,2 мең балага исәпләнгән мәктәп 1,4 миллиард сум торса, хәзер 2 миллиард сум кирәк. Бу – зур ресурслар, – диде Президент.

Ул шулай ук республикада күпбалалы гаиләләр өчен төзелештә уңайлыклар булдыру проблемасының хәл ителмәвен әйтте. «Бушлай җирләр таратылса да, анда үсеш юк, диде. 5–6 ел элек башкарылган эшләр хисабы буенча уңайлыклар тудыру өчен 40–45 миллиард сум кирәк иде. Бу – бик зур сан. Федераль ярдәмнән башка гына моны башкарып чыгу җиңел түгел, – диде ул.

Коронавирус темасы да читтә калмады. Авыручыларны тернәкләндерү өчен шартлар җитәме? Рөстәм Миңнеханов ковидтан соң тернәкләндерү мөһим икәнен әйтте. Казанда 7 нче хастаханә базасында заманча җиһазлар белән җиһазландырылган дәвалау-тернәкләндерү үзәге ачылган. Республика шәһәрләрендә кирәкле инфраструктура булдырыла. Коронавирус үлүчеләр саны артуына, уртача гомер озынлыгына йогынты ясаган. Димәк, вазгыятьне яхшырту өчен бала табарга кирәк. Берне түгел, икене, өчне...

Сәрия МИФТАХОВА

ЯРДӘМСЕЗ БУЛМЫЙ


tatarstan.ru

Икътисади вазгыять

Эшмәкәрләргә, IT-белгечләргә ярдәм, дарулар җитештерүгә яңа таләпләр... Россия Хөкүмәте утырышында килеп туган вазгыятьтә ил икътисадына ярдәм чаралары турында сөйләштеләр. Киңәшмәне Премьер-министр Михаил Мишустин уздырды.

«Икътисадтагы вазгыять тиз арада нәтиҗәле карарлар кабул итүне таләп итә. Министрлар Кабинеты ресурсларны тиз арада бүләргә һәм мөһим мәсьәләләр буенча тиз арада карарлар кабул итәргә мөмкинлек биргән өстәмә вәкаләтләр алачак», – дип белдерде Мишустин. Шул рәвешле Хөкүмәт утырышында икътисадка кагылышлы берничә җитди карар кабул ителде.

Аерым алганда, 10 марттан башлап шәхси эшмәкәрләр, кече һәм урта эшмәкәрлек оешмалары өчен планлы тикшерүләргә мораторий кертелә. Ул агымдагы елның 31 декабренә кадәр гамәлдә булачак. Андый тикшерүләрне кешеләр тормышына, сәламәтлегенә куркыныч янаган очракларда гына яңарта алалар.

Моннан тыш «Хезмәт өчен түләү фонды (ФОТ) 3.0» программасы да озайтыла. Билгеле булганча, аның кысасында эшмәкәрләр түбән ставка белән кредит рәсмиләштерә ала. Узган елның 1 ноябреннән 31 декабренә кадәр генә дә әлеге программа буенча 89 миллиард сумга 26,3 мең кредит килешүе төзелгән. Әлеге оешмаларда 644 мең кеше хезмәт куя. Хөкүмәт утырышында узган ел әлеге программа кысасында алынган кредитларны субсидияләү өчен 6,2 миллиард сум акча бүлеп бирү тәкъдиме хупланды. Бу акча эшмәкәрләргә хезмәт хакын, аренда һәм коммуналь түләүләрне вакытында башкарырга мөмкинлек бирергә тиеш. Икътисади үсеш министры Максим Решетников сүзләренә караганда, хөкүмәт тарафыннан бирелгән субсидия, иң беренче чиратта, пандемия чорында эшчәнлеген 90 процент чамасында саклап кала алган җәмәгать туклануы, кунакханә бизнесы, спорт һәм мәдәният тармагы оешмаларына зур ярдәм булачак.

Моннан тыш, кече һәм урта эшмәкәрлек эшендә Тиз түләүләр системасын кулланган өчен компенсацияләү программасы да ярты елга озайтылачак. Дәүләт башлыгы йөкләмәсе буенча бу максатларга 500 миллион сум бүлеп биреләчәк. Гыйнвар – июнь айларында әлеге сервис ярдәмендә товар яки хезмәт күрсәтү өчен түләгәндә салынган комиссияләр субсидияләр ярдәмендә тулы күләмдә капланачак. «Безнең тиз түләү системасы кибетләрдә банк карталары белән традицион исәп-хисап ясауга уңайлы һәм ышанычлы алмаш булып тора», – диде Михаил Мишустин үз чыгышында. Икътисади үсеш министры сүзләренә караганда, тиз түләү системасыннан файдаланучылар бер ай эчендә уртача 36 процентка арта бара. Максим Решетников моны программадан файдаланучылар саны арту белән аңлата. Әйтик, узган ел тиз түләү системасыннан файдаланучылар саны биш тапкыр артып, 34 мең субъектан 161 меңгә җиткән.

Хөкүмәт утырышында яңгыраган тагын бер яңалык салым түләү мәсьәләсенә кагыла. Аерым алганда, хөкүмәт һәм төбәкләр салым түләү срокларын озайту турында карар кабул итә алачак. «Яңа тәртип 2023 ел дәвамында гамәлдә булачак», – диде Михаил Мишустин. Хөкүмәт 1 марттан кыйммәтле металларга НДСны гамәлдән чыгару турындагы карарны да хуплады. 4 мартта закон проектын Дәүләт Думасы карарга тиеш. Мишустин фикеренчә, мондый кертемнәр валюта сатып алуга яхшы алмашка әверелергә мөмкин.

IT-белгечләргә дә ярдәм вәгъдә итәләр. Әлеге тармакта хезмәт куйган белгечләрнең торак шартларын яхшырту, аларның хезмәт хакын арттыру, ташламалы кредитлар бирү һәм салым ташламалары белән тәэмин итү өчен грантлар биреләчәк. Моннан тыш, әлеге оешмаларда эшләүче һәм 27 яшькә җитмәгән хезмәткәрләрнең хәрби хезмәткә чакырылу вакытын кичектереп торачаклар.

Михаил Мишустин дарулар белән тәэмин итүгә махсус режим кертелүен дә хәбәр итте. «Без безнең илдән санкцияләргә кушылган илләргә дару чыгаруга да чикләүләр кертә алачакбыз», – диде ул.

Белмәү кыйммәткә төшмәсен

Машинасы техник күзәтү узмаган йөртүчеләргә 2000 сум күләмендә штраф сала башладылар. Диагностика картасы булмаган техника белән идарә иткән өчен 1 марттан әнә шундый кагыйдә гамәлгә керде.

Билгеле булганча, узган ел ахырында Россиядә транспортка мәҗбүри техосмотр уздыру гамәлдән чыгарылды. Әмма бу яңалык шәхси куллардыгы җиңел машиналарга гына кагыла.

Исегезгә төшерәбез: таксига, автобус, йөк автомобиленә һәм оешмалар карамагындагы җиңел транспортка техник күзәтү уздыру мәҗбүри булып кала.

Моннан тыш конструкциясенә үзгәреш кертелеп, яңадан теркәү узган транспорт чараларының да диагностика картасы булырга тиеш. Дүрт елдан артык кулланылышта булган автомобильләрне хуҗасы алмашыну сәбәпле кабат теркәгәндә дә техосмотр узарга туры киләчәк, дип кисәтәләр Татарстанның ЮХИДИ идарәсендә.

Диагностика картасының гамәлдә булу вакыты турында мәгълүматларны Дәүләт автомобиль инспекциясенең рәсми сайтыннан табарга мөмкин.

Илдар Мөхәммәтҗанов

КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык намуслы хезмәте, республикада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү системасын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең Кама Тамагы филиалы бүлеге башлыгы **Гайнуллина** Гөлфирә Заһир кызы; җәмәгать туклануы системасын үстерүгә һәм халыкка югары культуралы хезмәт күрсәтүне тәэмин итүгә зур өлеш кертүе өчен «Опен Сити Ресторан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Саттарова** Наилә Фәез кызы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, республикада телевидение һәм радио тапшырулары чараларын үстерүгә һәм камилләштерүгә зур өлеш кертүе өчен «Россия телевидение һәм радиотапшырулар челтәре» федераль дәүләт унитар предприятиесенең «Татарстан Республикасының радио-телевидение тапшыру үзәге» филиалы җитештерү-техник бүлеге инженеры **Смирнова** Вера Николаевна; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, республикада әйләнә-тирә мохитне һәм хайваннар дөньясын саклауны тәэмин итүгә зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты каршындагы иҗтимагый совет әгъзасы **Макаров** Владимир Иванович; республика мәнфәгатьләрендә күпьеллык намуслы хезмәте өчен хезмәт ветераны **Шиһапов** Фидаил Әүхәддин улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе **Балтусова** Олеся Александровна, «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең Теләче филиалы бүлеге башлыгы **Вилданова** Гөлнар Илтөзәр кызын, «Россия почтасы» акционерлык җәмгыяте «Татарстан почтасы» федераль почта элемтәсе идарәсенең Казан районара почтамты почта аша җибәрелә торган әйберләрне һәм матбугатны сортларга бүлү һәм эшкәртү Биектау участогының 422723 Алан-Бәксәр почта элемтәсе бүлекчәсе почтальоны **Гафиятуллина** Халидә Шәүкәт кызы, «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры **Мозаффарова** Ленара Әкъмәлетдин кызы, «Россия почтасы» акционерлык җәмгыяте «Татарстан почтасы» федераль почта элемтәсе идарәсенең Казан почтамты 420043 Казан почта элемтәсе бүлекчәсе почтальоны **Мухлина** Надежда Андреевна, «Кичектергесез ярдәм күрсәтергә чакыру хезмәте – 112» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең дежур сменаларны кичектергесез ярдәм күрсәтергә телефон аша чакыруларны кабул итү һәм эшкәртү буенча белгече **Новикова** Ольга Александровна, «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры урынбасары **Порфирьева** Светлана Анатольевна **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең гамәли математика һәм информатика кафедрасы профессоры **Новикова** Светлана Владимировнага **«Татарстан Республикасының атказанган югары мәктәп хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенең проектларга идарә бүлеге башлыгы **Сәмигуллина** Елена Борисовнага, «Таттелеком» гавами акционерлык җәмгыятенең мәгълүматларга идарә үзәге биллинг исәп-хисапларын норматив-белешмә ягыннан тәэмин итү төркеме җитәкчесе **Шәйдуллина** Гөлназ Сәмигулла кызына, Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының элемтә хезмәтләрен үстерү бүлеге әйдәүче белгече **Шәймуллина** Фәридә Галиулла кызына, «Таттелеком» гавами акционерлык җәмгыятенең Казан электр челтәре идарәсе эксплуатация-техник бүлеге техник исәп һәм паспортлар бирү төркеме җитәкчесе **Эскина** Елена Наумовнага **«Татарстан Республикасының атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Әйтеп кенә бактым

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

Күзәнәк

Бүгенге ирләр һәм хатын-кызлар арасындагы мөнәсәбәт, гаиләләр турында бер-бер сүз әйтергә күптән тел кычытып йөри. Әмма буш сүз белән тел кашып файда юк бит. Шуңа күрә язарга утырыр алдыннан төрле сораулар биреп танышларны, дус-ишләрне шактый аптыратып бетердем. Ни өчен бүген кулларыннан эш килгән, тормышта үз урынын тапкан, үз тормышын көйләгән гүзәл затлар үзенә пар таба алмый йөри? Ә көчле зат саналган ирләр ни өчен гаилә корудан курка башлады? Әлеге сорауларга күпмедер дәрәҗәдә җавап бирә алам кебек, әмма өздереп кенә әйтергә шикләндерә. Элгәрәк мин: «Яшьлек җүләрлеге белән өйләнергә яки кияүгә чыгып калырга кирәк», – дип сөйләнеп йөрдем. Тик статистикага күз салсаң, шушы «җүләрлек» шактый аяныч нәтиҗәләргә китерә икән, ягъни илдә аерылышучылар саны инде менә шактый еллар арта бара, күбесенең характерлары туры килеп бетми икән. Сүзем коры булмасын өчен әйтим: мәсәлән, 2021 елда таркалган гаиләләр саны аннан алдагы елга караганда 564033тән 644207гә җиткән. Ә кавышулар кимеп бара икән.

Бу хәлне заман авырлыгы, пандемия зәхмәте белән бәйләп тә аңлатмакчы булалар. Безнең кайчан җәннәттә яшәгән бар соң? Гаилә кору, нәсел калдыру элек-электән табигый, кирәкле эш саналган. Хәзер «җәмгыять күзәнәге» булган гаиләләр көчсезләнә башлады кебек. Көчсезләнү генә түгел, аларның барлыкка килүе дә кимеде.

«Көчле» һәм «гүзәл» затларга килгәндә, бездә вазыйфалар да алышынып бара кебек. Нужәли, яңадан матриархат чорына керәбез инде?! Баш мие ярымшарларында күзәнәкләр үз урыннарын алыштырдылар микән әллә? Хатын-кыз көчлерәк кебек хәзер. Җәмгыятьтә кулыннан эш килгән, акыллы, үз тормышын үзе алып бара ала торган гүзәл затларга муллык кебек. Элек алар тормышта терәк булырлык ир турында хыяллансалар, ирләр гаилә учагын сүндерми тотарлык хатын-кыз эзләделәр. Хатын ул акылбелем ягыннан да бераз кайтыш булырга тиеш кебек иде. Бу – электән килгән, беркайда да язылмаган, әмма үтәргә тиешле закон, кагыйдә. Гаиләдә «ир – баш, хатын – муен» саналды. Әмма хәзер хатын – баш, ир муенга әйләнеп бара кебек. Ир заты көчле хатын янында үзен хуҗа итеп тоя алмаячак. Бәлки, ул шуннан куркадыр да дигән шик бар. Әгәр шулай икән, димәк, хатын-кыз үзенең язылмаган законда каралган төп миссиясен үтәргә тиеш була. Тик иренең күзенә генә карап торырлык гүзәл затлар кими бара, ә хатынының күз карашыннан куырылып, кечерәеп кала торган ирләр ишәя кебек.

Әле артык хыялланып китеп, бәлки, ерак киләчәктә «җәмгыять күзәнәге» булган гаиләләрнең дә кирәге калмас, дип саташкалап та куям. Ир – үз, хатын-кыз үз рәхәте өчен яши башлар да вәссәлам! Бу фикерне бер дустыма да әйтеп караган идем, ул: «Гаилә булмагач, балалар тумагач, Җир йөзендә адәм заты да калмый, җәмгыять дигәннәре дә бетә бит», – диде. Мин аның саен «саташам». «Хәзер фән бик алга китте, кеше күзәнәкләрдән клоннар ясар, шактый эшне роботлар алыштырыр. Гаилә кирәк икән, бер җенесле кешеләр гаилә корып, рәхәтләнеп яшәрләр. Дөнья шуңа таба бара шикелле», – дим. Бу хакта уйлаганда: «Привет, дауатика», – дип авыз ерган клон балалар күз алдына килеп китте. Дустым исә миңа аптырап карап торды да чигәсенә бармагын әйләндереп күрсәтте. Аңа, әлбәттә, үпкәләмәдем. Әйткәннәрем бүген, чыннан да, саташу, булмастай бер хыял гына бит. Һәрхәлдә, бүген шулай уйлата, чукынчык. Әмма җәмгыятьнең күзәнәге булган гаиләләрнең күпләп таркалуы, бала табуларның кимүе барыбер ямьсез итеп күңелне кытыклап тора. Күңелсез уйларны читкә куям. Редакциядә эшләүче берсеннән-берсе уңган, чибәр кызларга карыйм да, табигать барыбер үзенекен итәчәк, дип күңелне тынычландырам.

ШЫГЫРДАГАН КӨПЧӘКНЕ БЕРЕНЧЕ АЛЫШТЫРАЛАР

Безнең тормышка бәреп кергән вакыйгалар фантастиканы хәтерләтә бүген, куркыныч төшне... Барысы да көтелмәгәнчә кебек: кисәк кенә башланган махсус хәрби операция дә, безне аяктан егарга тиешле санкцияләр дә, моңарчы тарихта күрелмәгән изоляциядә калуыбыз да...

en.kremlin.ru

Менә соңгысы, изоляция дигәне көчәя соңгы көннәрдә: Россия очкычларына Европа күгендә очарга ярамый, АКШ яңа гына шундый тыюлар кертеп ята, Бөекбритания портларында санкцияләр астындагы ил корабларына тукталу тыелды. Чып-чын сюрреализм инде менә. Бу юллар язылыр алдыннан гына АКШта Байден чыгыш ясады. Россияле олигархларның җинаятьләрен тикшерә башлячакларын, малларын тартып алырга әзерләнәчәкләрен белдерде. АКШның Юстиция министрлыгы махсус төркем төзеп, эшкә керешергә әзерләнә икән. «Без Европадагы союзниклар белән сезнең яхталарыгызны, элиталы торакларыгызны, хосусый очкычларыгызны тартып алу өчен көчләрне берләштерәбез», – диде Байден. Дөрес, Америка лидерының башы киткән инде, ул украинлылар белән иранлыларны бутады. Әмма аның кисәтүе – чын кисәтү. Польшада Россия милкен конфискацияли башладылар инде. Илчелекнең мәктәбенә кадәр тартып алалар.

Көтелмәгән хәл, әйеме? Юк, бу юлларның авторы көтелмәгән дип әйтмәс иде. «Ватаным Татарстан»ның сайтында 2020 елның 1 май датасы белән безнең «Финанс кыенлыклар шартында ничек яшәргә?» дигән язмабыз эленеп тора. Анда мондый юллар бар: «COVID-19 – без күрергә язган кыенлыкларның беренче сериясе генә бит әле. «Кино»ның дәвамы тагын да киеренкерәк һәм дәһшәтлерәк булачак. Эшсезлек артуга, акчасызлыкка дөнья сәясәтенең тектоник плитәләре хәрәкәткә килү нәтиҗәсендә туган тетрәнүләр килеп кушылачак. Чынбарлыкка аек күз белән текәлеп карыйк: кыен һәм бик кыен булачак». «...сәясәтнең тектоник плитәләре хәрәкәткә килү нәтиҗәсендә туган тетрәнүләр килеп кушылачак», – дигән сүзләргә игътибар итегез әле. Аңлаган кешегә без пандемиядән соң геосәяси киеренкелеккә корылган тетрәнүләр башланасын әйттек. Календарьда 2020 ел иде без кисәткәндә, коронавирустан куркып өйләргә качкан идек. Пандемия тәгәлләнеп килә инде, мантыйкый рәвештә аны дәүләтләр һәм блоклар арасындагы конфликтлар алыштыра. Әле күптән түгел генә, 2021 елның декабрендә «Караңгылык таң алдыннан көчәя» дип, яңа елга фаразлар язган идек. Без ул фаразларда сәясәтнең тектоник плитәләре кайсы төбәкләрдә үзара бәрелешәсен төгәл итеп әйттек. «Әмма 2022 елда, мөгаен, төп вакыйгалар Көнбатыш – Россия, Көнбатыш – Кытай ассылыгында барыр. Әгәр конфликт Көнбатыш – Кытай мәйданында көчәйсә, Россиягә Көнбатыш белән аркадашлык итәргә туры киләчәк. Учак безнең чикләрдә ягылса, бер дә яхшыга түгел», – дидек. Әйтеп карагыз, кисәтмәдегез, дип. Редакциядә гел сүгәләр бу юлларның авторын: «Кешеләрне куркытасың», – диләр. Юк, бәгырьләрем, куркытмыйм, кисәтәм. Бу кисәтүгә колак салып, ун-унбиш көн элек кенә булган барлык акчагызга долларлар сатып алсагыз, матди хәлегезне ярыйсы гына яхшыртыр идегез. Башка кайбер чаралар да күреп була иде. Әмма поезд китте инде.

Әйдәгез, хәзер аз гына алга таба ничек яшәргә дигән сорауга бергәләп җавап эзләп карыйк. Бер нәрсәне ассызыклыйбыз: державаларның үзара чәкешүе – тарихи котылгысызлык ул, шуңа күрә гаепле эзләп тормыйбыз. Фаталь әйберләргә кешеләр тәэсир итә алмый, алар, бигрәк тә лидерлар тарих сәхнәсендә үзләренә язылган рольне башкаралар гына. Фаҗигале сукмактан тәкъдирләренә буйсынып атлыйлар. Гамәлләре өчен җаваплы алар, әлбәттә, әмма җавапка тартучылар без түгел.

Килеп туган вазгыятьтә Россия лидеры Владимир Путин үзеннән таләп ителгәннәрне башкара инде. Сишәмбе көнне генә ул финанс тотрыклылыгын тәэмин итү өчен өстәмә икътисади чаралар турында указга кул куйды. Аңлый торгансыздыр инде: указ белән генә доллар курсын да стенага кадаклап булмый, бәяләрне дә киштәгә беркетә алмыйсың. Көнбатыш санкцияләрен без айдан-айга ныграк тоячакбыз. «Российская газета», санкцияләрдән зыян күргән тармакларда меңләгән яңа эш урыны пәйда булачак, дип белдерә. Бу юлларның авторы бераз гына башкачарак фаразлый. Эш урыннары булыр ул булуын, квалификацияле һәм югары технологияле продуктлар җитештерергә яраклы белгечләр җитмәс. Булганнары да чит илгә кыяклау ягын карый хәзер. Креатив класс Россиядән качу идеясен байрак итеп күтәрә социаль челтәрләрдә. Менә аларны тотып калу һәм эш фронты белән тәэмин итү – җитәкчелекнең бурычы. Цифрлаштыру министрлыгы «ай-ти» кадрлар өчен өстенлекләр вәгъдә итте. Тик яшьләр бик егылып ук китмиләр әле ул өстенлекләргә, чит җирләрдә үзләренә тору урыны эзлиләр һаман да. Аһ, белсәләр иде алар үзләре китәргә теләгән илләрнең киләчәктә зур бәрелешләр мәйданына әвереләсен. Геосәяси тетрәнүләр Россия өстеннән гөрелдәп узгач, бәрелеш Көнбатыш белән Якын Көнчыгыш арасында башланачак дип фаразлый, мәсәлән, бу юлларның авторы. Ялгышса, бик шат булачак. Шуңа күрә илдән китәргә теләүчеләргә маршрутны бик уйлап сайларга киңәш итә. Бәлки, Россиядә калып тору (вакытлыча гына булса да) яхшырактыр. Дөрес, Россия белән идарә итү форматы тамырдан һәм кискен үзгәрер (без бөтенләй уйламаган рәвештә), срокларын гына әйтеп булмый. Әлегә илнең югары җитәкчелеге халык ачыкмасын һәм бөлгенлек ярында аякларын салындырып утырмасын өчен булдыра алганча чаралар күрә. Әйтик, чәчүлек җирләрне 1 миллион гектарга ишәйтергә ниятлиләр. Россия өчен миллион гектар зур сан түгел, әмма анысын да эшкәртү өчен эшче куллар табасы бар әле. Җәй, Аллаһ теләсә, яхшы килер, уңыш мул булыр дип өметләник. Бер нәрсәгә игътибарны юнәлтәбез: ашлык экспортлаучы ике төп ил – Россия белән Украина үзара мөнәсәбәтләрен ачыклый, бу дөньяның башка почмакларында, аеруча Якын Көнчыгышта матди хәлне катлауландырырга ихтимал.

Барлык илләр дә безгә ишекләрен шап итеп ябып бетермәделәр. Төркия үзара хезмәттәшлек ягында. Технологик яктан кызу темплар белән үсеп баручы бу ил Көнбатыш сатудан баш тарткан кайбер технологик продуктлар белән безне тәэмин итә алыр иде. Димәк, хәл катлаулы, әмма баш китәрлек түгел.

Гади кеше – ялланып эшләп тамагын туйдыручы халыкка нишләргә? Һәркем үзе өчен файдалы булган гамәлгә чытырдап ябышырга тиеш, билгеле. Билләрне кысып буарга туры киләчәк, ансыз гына булмый. Менә шул чакта зарланмаска! Инглизләрнең «Шыгырдаган көпчәкне майлыйлар» дигән әйтеме бар-барын. Әмма хәзерге вазгыятькә бер дә туры килми. «Шыгырдаган көпчәкне беренче алыштыралар», менә шуны истә тотыйк.

Нью-Йорк университетының икътисад профессоры Нуриэль Рубини дигән кеше бар бит әле. Кризисларны фаразлау белән шөгыльләнә. Ул әйтә: «2022 ел алдагысыннан өч фактор: көчәюче инфляция, пандемиянең дәвам итүе һәм геосәяси киеренкелек сәбәпле начаррак булачак», – ди. Без әйткәнне әйтә инде асылда.

«Финанс кыенлыклар шартында ничек яшәргә?» дигән язмада: «Бердәнбер ышанычлы актив – алтын, билгеле. Доллар станогы әйләнгән саен, алтын бәясе үсә», – дип язганбыз. Акчасы барлар өчен яхшы киңәш булган иде ул чакта. Алтын бәясе 2000 долларга якынлашып килә, доллар бәясе дә ике тапкырга якын үсте. Алтын икеләтелгән табыш биргән ике елдан азрак вакыт эчендә. Кайсы актив шуның кадәр табыш бирә ала? Әмма алтынсыз да яшәп була, күңелне төшермәсәң.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

ТОТЫП КАРАМЫЙЧА ГЫНА

ФЕРМЕРЛАР ИНТЕРНЕТ СӘҮДӘГӘ КУШЫЛЫРГА АШЫКМЫЙ

Россиядә, шул исәптән Татарстанда да электрон сәүдә үсә. Узган ел, мәсәлән, маркетплейсларда теркәлгән республика кибетләренең саны җиде тапкыр арткан. Тик алар арасында авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүче фермерлар, эшмәкәрләр генә аз. Сәбәп нидә? «ВТ» хәбәрчесе электрон сәүдә мәсьәләсен өйрәнде.



Илдар Мөхәммәтҗанов

Алардан башка үсә

AliExpress Россиянең дәүләт хакимияте органнары белән элемтә буенча вице-президенты Сергей Лебедев биш ел эчендә Россия базарының электрон сәүдәсе ел саен якынча 30 процентка үсәчәген фаразлый. Аның сүзләре буенча, соңгы 2–3 елда ул электроника сату хисабына алга киткән. «Ләкин хәзер базар үзгәрә, – дигән иде ул Икътисад министрлыгының еллык коллегиясе вакытында. – Бүген электрон сәүдә өчен никадәр ешрак сатып аласың, шуның кадәр яхшырак. Ә моңа азык-төлек һәм халык көн саен куллана торган товарлар сатып ирешергә мөмкин. Шулай ук иң күп һәм еш алына торган товарлар исемлегендә җиңел сәнәгать продукциясе дә бар. Ә бу өлкәдә Татарстан көчле».

Гомумән алганда, федераль үзәктән кала, Татарстан субъектлар арасында лидер. Соңгы елда республика маркетплейсларда теркәлгән кибетләр саны буенча Идел буе федераль округында беренче урынга чыккан. Шулай ук товарларны сату да AliExpress Россия мәйданында биш тапкыр арткан. Шунысы кызык: сату ешлыгы тугыз тапкыр арткан. Әлеге платформада 2000нән артык Татарстан сатучысы 250 меңнән артык төрдәге товар тәкъдим итә.

– Ике ел элек электрон сәүдә базары тәэмин итеп торучы (поставщик) базары булса, ягъни игътибар сатучыга һәм җитештерүчегә бирелсә, хәзер ул сатып алучы базарына әйләнде. Пандемия моны күп тапкыр тизләтте. Без җитештерүчедән бигрәк, беренче чиратта кулланучыга якын булырга кирәклеген аңладык, – диде Сергей Лебедев.

Алга карап эш йөртүчеләр өчен әлеге мәйданда мөмкинлекләр бар кебек. Тик традицион маркетплейсларда фермерлар гына аз. Моны фермер, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кооперативлары ассоциациясе президенты Камиир Байтемиров да инкарь итми. Аның сүзләренчә, бүгенгә фермерларның 10–12 проценты гына үз товарларын интернет аша сата. Маркетплейсларга чыкканнар тагын да азрак.

– Фермерлар гадәттә үз товарларын күпләп сату ягын карый. Моннан тыш, күпчелегенең үз сайтлары бар, андыйлар үз кулланучылары белән шәхсән эшли. Маркетплейсларга да керүчеләр бар, ләкин анда сату-алу бик сүлпән бара. Чөнки безнең халык күреп, тотып, карап алырга күнеккән. Җитештерүчеләргә дә бу мәсьәләдә өйрәнергә дә өйрәнергә кирәк әле. Без үз ягыбыздан төрлечә ярдәм итәргә тырышабыз анысы. Укулар оештырабыз. Бу очракта республикада логистик үзәкләр кирәк. Ләкин алар зур булырга тиеш түгел, чөнки андыйларда индивидуальлек бетә, – ди республиканың баш фермеры.

Сату өчен уңышлысы – социаль челтәрләр

Аның каравы авыл хуҗалыгы продукцияләрен сатар өчен махсуслашкан интернет платформалар барлыкка килде. 2020 ел ахырында Россельхозбанк «Свое Фермерство» экосистемасын һәм «Свое Родное» маркетплейсын эшләтеп җибәргән иде. Бүген фермерлар арасында, үз сайт һәм социаль челтәрләреннән кала, иң популяр платформалар менә шулар. Узган ел экосистемада республиканың 400 җитештерүчесе теркәлгән, ә «Свое Родное» маркетплейсында 200дән артык фермер үз онлайн-киштәләрен булдырган. Цифрлы платформаларны эшләүчеләр сүзләре буенча, биредә вак фермерлар да, эре компанияләр дә үз продукцияләрен тәкъдим итә ала. Барысы да уңайлы эшләнгән. Үз товарларын сату өчен фермерларга сайтларда теркәлергә генә кирәк. Һәм бу бушлай. «Свое Родное» маркетплейсында сөт ризыкларыннан алып баллы ризыкларга кадәр сатыла.

Фермер Кадрия Лотфуллина – замана белән бер адымда атлаучы эшмәкәр. Ул үз продукциясен (аерым алганда, кош ите, ярымфабрикатлар, ысланган ризыклар) «Свое Родное» һәм «Озон Экспресс» платформалары аша сата, шулай ук ваклап сату нокталарына тарата. Болардан кала үз кибетләре бар.

– Интернет белән дуслыгыбыз 1,5 ел элек башланды. Әлеге платформаларга кергәндә беренинди дә авырлыклар булмады, чөнки Россельхозбанк бик нык ярдәм итте. Киңәшләрен бирделәр, уңайлы юлларын күрсәттеләр. Сату белән моңа кадәр дә проблема юк иде. Платформага теркәлгәч, тагын да артты. Ләкин катырылган продуктлар билгеле бер шартларда сакланырга тиеш. Бу яктан караганда, безгә маркетплейслар уңайсыз. Ләкин киләчәктә авыл хуҗалыгы продукциясен интернет киңлекләрендә күбрәк күрербез дип уйлыйм. Барлык технологияләр алга киткәндә, фермерлар гына артта кала алмас, – ди эшмәкәр ханым.

Апас районында суган һәм башка яшел тәмләткечләр үстерүче фермер Наилә Әхмәдиева да әлеге платформаларның берсендә теркәлгән. Тик аның фикеренчә, фермерлар өчен иң уңышлы юл – үз товарларын социаль челтәрләр аша сату.

– Безнең республикада фермерларның күпчелеге үз товарларын социаль челтәрләр аша сата. Иң популяр сату мәйданы ул. Моны үзебездән генә дә әйтә алабыз. Сату максатыннан түгел, үз эшебезне күрсәтеп, фото һәм видеолар ясап, интернетка куйганнан соң ук күп заказлар килә башлый. Ягъни күпчелек уңышлы фермерлар өчен шәхси брендны танытыр һәм сату өчен социаль челтәрләр – зур ярдәм, – ди Наилә Әхмәдиева.

Эшмәкәр ханым әйтүенчә, фермерларга маркетплейсларда сату авыррак, чөнки монда саклану вакыты 14 көннән күбрәк булган продуктларны гына тәкъдим итү отышлы. Он, шикәр, көнбагыш мае, төрле ярмалар кебек продукцияне сатарга була әле. Ә тиз бозыла торган продуктларны сатып алучыларга китереп бирү өчен «Озон Экспресс» платформасы эшли. Монда бер заказ белән бөтен төрдәге ризыкларны алырга мөмкин. Шунысы уңайлы.

– Ләкин аның бер начар ягы бар: платформага продукция арадашчылар арасында үткәрелгән тендер нигезендә генә эләгә. Ә анда көндәшлек көчле һәм «Озон Экспресс»ка арзан бәядәге товар алына. Ә маркетплейсларда товарның үз бәясен кую мөмкинлеге бар. Һәм, мәсәлән, бер товарның берничә җитештерүчесен тәкъдим итәргә мөмкин. Сатып алучы алар арасыннан үзе сайлап ала. Алар шуның белән отышлы. Ләкин продукциянең саклану вакыты чикле булганга, без анда керә алмыйбыз, – ди ул.

Икенчедән, фермер фикеренчә, күпләрнең продукцияне сату белән проблемалары юк. Киресенчә, күләмнәрен арттыру белән бәйле авырлыклар бар.

– Без дә күбрәк сата алыр идек, ләкин андый мөмкинлегебез юк. Күләмне арттыру турында уйлыйбыз, тик хәзерге шартларда ничек булыр, әйтүе кыен. Арттырасы урынга, саклап калу проблемасы барлыкка килмәсә ярый инде, – ди ул.

Шул ук вакытта фермерлар «Свое Родное» платформасының да уңайсыз ягын әйтә: сатып алучыга һәр фермер белән аерым сөйләшергә туры килә, ди алар. Ягъни бер фермердан – ит, икенчесеннән – сөт, өченчесеннән яшелчә сатып алырга кирәк булачак.

– Фермерларның күпчелеге кибетләр челтәренә (бу очракта шул ук маркетплейсларга) җитәрлек күләмдә продукция тәкъдим итәргә өлгерми. Бу очракта кооперативларга кереп эшләү уңайлы. Беренчедән, пайчылар төрле продукция җитештерә, икенчедән, мәсәлән, берсенең продуктивлыгы кимеп киткәндә, икенчесе ярдәмгә килә ала, – дип саный Наилә Әхмәдиева.

Тотып карамыйча, ышанмас

Хәер, электрон сәүдәгә, төгәлрәк әйтсәк, ит, сөт, йомырка кебек авыл хуҗалыгы продукциясен интернеттан гына заказ биреп китертергә халыкны да ияләштерәсе бар әле. Соңгы елларда бирелә сатып алулар артса да, фермер продукциясенә сорау зур түгел. «ВТ»ның социаль челтәрләрендә һәм авторның «Инстаграм» сәхифәсендә уздырган сораштыру нәтиҗәләре әнә шуны күрсәтә.

Укучыларыбызның җавапларыннан аңлашылганча, күпчелек кеше ышанычлы кешеләрдән алынган ризыкларга өстенлек бирә. Бәяләре мөһим булса да, ашаган ризыкның экологик чиста, сыйфатлы булуы тагын да зуррак роль уйный. Ә менә «тиз генә китереп бирәбез» диючеләргә артык исләре китми икән. Сораштыруда катнашучыларның күпчелеге ит, сөт, йомыркаларны авылдан алып киләбез дисә дә, фермер товарлары сатыла торган махсус кибетләрдән, ярминкәләрдән сатып алучылар да шактый. Ә менә интернеттан заказ бирүчеләр бик аз булып чыкты. «Сирәк яки бер дә алган юк», – дип җавап бирүчеләр күпчелекне тәшкил итә. Моның сәбәбе кулланучылар интернетта тәкъдим ителгән товарларның сыйфатлы булу-булмавына ышанмау һәм ияләшмәгән булу белән аңлата.

Кыскасы, безгә авыл хуҗалыгы продукциясен интернетта сатарга да, сатып аларга да өйрәнәсе бар әле.

Зөһрә САДЫЙКОВА

КЕШЕГӘ... КЕШЕ КИРӘК!

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Бер-береңдә кеше күрергә өйрәнгәндә генә кеше булырсың. Язучы, шагыйрь Александр Радищевның шундый сүзләре бар. Хәзерге вазгыятькә бу бигрәк тә туры килә. Гаепсездән гаепле, теге яисә бу сәяси, дөньяви карашың өчен дошман булып куярга да күп кирәкми. Иң куркынычы – үз кавемеңдәгеләргә таш ату. Туры мәгънәдә түгел, билгеле. Сүз белән яралау, куралмау күренеше социаль челтәрләрдә, гадәти тормышта, эш урынында, хәтта гаилә әгъзалары арасында күзәтелә хәзер. Барыбызның да адәм баласы икәне дә онытыла...

Төптәнрәк уйлап карасаң, хисләрнең бер мәлдә ташып чыгуына күптәннән җыелган сәбәпләр дә тәэсир итә. Коронавирус пандемиясе тормышны тамырдан үзгәртте, җирле вакыйгалар җанны талады, Олимпия уеннарындагы гаделсезлекләргә исебез китте. Хәзер уйларыбызны башка борчулар ялады...

Хисләр өстен чыкса, нишләргә?

Мондый кискен реакциянең табигый булуын искәртә белгечләр. Борчу-төшенкелек хисләре вазгыять киеренке төсмер алганда аеручa чагыла башлый.

Психолог-консультант, шәхес үсеше тренеры Айнур ХӨСӘЕНОВ әйтүенчә, дөньяга инстинктив-хисси мөнәсәбәт белән карау һәрвакытта да аңлы эш итүгә караганда беренчелрәк тора.

– Иң мөһиме – бу курку-борчу хисләре ниндидер җитди эш-гамәлләргә китермәсен. «Беренче чиратта нишләргә кирәк соң?» дигән сорауга... бернәрсә дә эшләмәскә дип җавап бирер идем. Тирән итеп сулыш алырга, су йотып куярга, битне юарга, ятып, утырып, басып торырга, әмма моннан да артыгы түгел. Вакыйгалар ташкыны аркасында килеп чыккан хафалануны бетерү өчен үзеңне негатив чыганагыннан аерырга кирәк. Бу – иң мөһиме! Социаль челтәрләрне, телевизорны азрак карарга, вазгыятьне тагын да кискенләштерә торган кешеләр белән аралашмаска, алардан ерагаерга. Мондый очракта сез файда китерердәй гамәл – коткы таратуны киметүгә өлеш кертү. Үзүзеңне кайгырту турында да онытмасак иде. Ашауэчүдән калмаска. Эчтәге борчуларны якиннар белән бүлешергә була. Монысы куркыныч вазгыять турында коткы тарату түгел, ә борчулар белән уртаклашу гына, таяныч эзләү юлы булып санала, – дип аңлата психолог.

Киеренке шартларда да тынычлык саклау мөмкин хәл. Ышанырга кыен да кебек, әмма бу чынлап та шулай.

– Борчу хисе тудырган сәбәпләр белән эшләргә өйрәнергә кирәк. Шәхси терапия үтәргә мөмкин. Ягъни белгечкә барып күренергә. Психологлар да кеше бит инде, алар да борчыла, бу хис торган саен арта да. Без дә белгечләргә йөрибез инде ул, – ди Айнур Хөсәенов та. – Махсус коткыга бирелергә ярата торган кешеләр бар. Андыйларны үзгәртеп булмый, алар инде паникага бирелергә күнеккән. Әйтүемчә, тынычлануның иң төп чарасы – тирән итеп сулау. Котылу юлын һич кенә дә хәмер һәм башка начар гадәтләр аша эзләргә ярамый. Әле алар хәлне катлауландырырга да мөмкин.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Зыян итмә!

Мәгълүмат күплеге белән көрәшеп булмый. Аны чикләргә генә мөмкин. **Практик психолог, психология фәннәре магистры Зөһрә КӘРИМОВА** әйтүенчә, хәзерге вазгыятьтә күңелне борчуга сала, яшәргә комачау итә торган төп чыганак (ничек кенә парадокс буларак яңгырамасын) – ул мәгълүмат ала торган каналлар.

– Кеше ял итми, тормыштан, һәр туган көннән ләззәт алмый башлый. Елмаю урынына усаллык, агрессия, гаеп чәчә. Негатив китерә торган мәгълүматтан качып котылып булмый, аны барыбер укыйсың, күрәсең, ишетәсең инде. Андый очракта исә боларның барысын да күңелгә якын алмаска киңәш итәбез, – ди белгеч. – Әйе, әйтәсе җиңел, әйе, куркыта. Әмма андый мәгълүмат белән танышып кына тормыш җиңеләяме әллә? Үзебезгә генә начар ясыйбыз бит. Бу коронавирус инфекциясе очрагындагы кебек. Чир пәйда булуга кешеләрне коткы хисе биләде, очрашырга, аралашырга курка башладык, арада элемтә югалды.

Кеше булып калу җиңел, ди психолог. Аның өчен иң элек кеше үзе белән гармониядә булырга, йөрәгендә мәхәббәт, игелек һәм тынычлык кебек сыйфатларны йөртергә тиеш.

– Үзебезне үзгәртүдән дөнья да үзгәрә. Сезгә карата ниндидер дорфалык, агрессия кулланыла икән, шул ук юлны сайлап, ачу белән җавап бирергә кирәкми. Таш атканга аш белән ат, дигән бик дөрес, гыйбрәтле сүзләр бар безнең халыкта. Шулай итсәгез, сезгә дә җиңел булачак, усал кыланган кеше дә үзенең хаксызлыгын таныячак. Бу бит декрет ялында озак утырган әни кебек. Ул да арыганга гына балаларына ярсый, кычкыра, – дигән фикердә Зөһрә Кәримова. – Мондый ярсу күренешләре булмасын өчен, эчке ресурсларны тутырып торырга кирәк. Бу ни дигән сүзме? Игелек кылу, кешеләргә карата мәрхәмәтле булу, мәхәббәт өләшү. Социаль челтәрләрдә дә мөмкин кадәр үзеңне позитив тотарга киңәш итәм. Башкаларга агу чәчмәскә, үзеңә карата да мондый алымны кулланырга юл куймаска.

Андрей КУРПАТОВ, психотерапевт:
– Кешелеклелек һәм аек акыл бик аз бездә. Бөтен кешеләрне бер-берсенә каршы котыртуга сәбәп тудыру өчен утка шырпы ташлау җитә. Минемчә, бу дөрес түгел. <…> Дөнья һәрдаим кризис, төшенкелек, сугыш, үзгәреш кичереп тора. Бу кешелекнең һәр чорында шулай иде. Безнең, әлбәттә, тарих башка кабатланмас диясе килә. Ә бу – иллюзия. Кеше шулай корылган: ул яңадан-яңа низаглар тудырып торачак. Моның нәтиҗәсе буларак һәр яңа чор буынына нигездән үзгәрешләр, инкыйлаб-сугышлар туры килә.
<…> Әгәр дә без эчке явызлыгыбызны аңламыйбыз икән, без, гомумән, яхшы кешеләр була алмаячакбыз. Мондый чорда кеше булырга өйрәнәсе иде: берәүгә дә начарлык теләмәскә, чөнки ул болай да җитәрлек. Бу – эчке сайлавыбыз. Шуңа күрә, бер яктан, безгә барыбыз да, вазгыятьнең барлык авырлыгын аңлап, бөтен хәлләр турында уйларга кирәк, ә икенче яктан, без беркемгә карата да нәфрәт хисе кичермәскә өйрәнергә тиеш.

(«Ютуб» каналындагы тапшыруыннан)

Психолог үзе дә күптән түгел Европа буенча сәяхәттән йөреп кайткан. Кешеләрдәге агрессиянең кискенләшүен шунда да сизгән ул.

– Украинадан бер гаилә, Россиядән булуыбызны аңлагач, сүз белән һөҗүм итте. Әлбәттә, әйткәннәреннән күңелдә юшкын калды. Психолог буларак, мин аны аңлыйм да, аларның хисләрен уртаклашам да. Әмма үз-үземне битәрләүгә кадәр барып җитмәячәкмен. Гаепсездән гаепле булу хисен кичерергә кирәкми, – ди ул. – Безгә бер-беребезне хөрмәт итәргә өйрәнергә кирәк. Хәзергә генә, барысы да тынганчы дип кенә түгел. Хөрмәт гел булырга тиеш!

P.S. Дөньясы да җайланыр, үз күчәренә кайтыр. Өметләник! Барысы да тынгач, әйткән сүзләребез, кылган гамәлләребез аркасында бер-беребезнең күзләренә карарга оят булмасын иде, шул гына. Җимерелгәнне төзекләндереп, купканны ябыштырып булыр. Сүздән калган яра гына төзәлмәс. Кеше булып каласы иде!

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Ярдәм кирәккәндә

Башкаладагы ышаныч телефоны: +7 (843) 571-35-71, +7 (843) 277-00-00

«Сердәш 129» психологик хезмәте телефоны: +7 (843) 279-55-80

«Ресурс» психологик-педагогик үзәге телефоны: +7 (843) 554-74-09

«Выбор» психологик хезмәт телефоны: +7 (843) 562-56-40, +7 (995) 008-95-81

«Фатыйма» хатын-кызлар үзәге: +7 (843) 246-44-01

Илкүләм психологик ярдәм күрсәтү хезмәтенең «кайнар элемтә» телефоны: 8 (800) 600-31-14, 8 (800) 2000-122 (балалар өчен), 8(800)222-55-71 (студентлар өчен)

brainbild.ru сайтында бушлай «туры эфир» һәм консультацияләр табарга мөмкин.

11 мартта сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә баш мөхәррир урынбасары **Гөлинә Гыймадова** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Пенсиягә өстәмә булырмы?

Миңа 90 яшь. 5 мең сум акча түләмәделәр. Пенсиям – 19200 сум. Ул 5 мең сум акча кайда йөри икән? Ничек алырга?

Нурзидә ИБРАҺИМОВА.
Зәй районы Кушъелга авылы

**Лилия Камалюкова,
Зәй Пенсия фонды идарәсе башлыгы урынбасары:**
– Андый өстәмә түләү булмады. Нурзидә Ибраһимова иренең пенсиясенә күчкән булган. Гаиләне туендыручы вафат булу сәбәпле бирелә торган пенсия ала ул. Күчкән чорда аңа шулай эшләү отышлырак булган, димәк. Моның өчен билгеле бер күләмдә (фиксированная. – **Ред.**) акча түләнә. Аңа башка өстәмәләр кушылмый. Бәлки, Нурзидә апа үз пенсиясендә калган булса, аңа түләүләр өстәлгән булыр иде.

P.S. Идарәдә архивтан кирәкле мәгълүматларны карарга вәгъдә бирделәр. Нурзидә апага аның өчен хәзер отышлы булган пенсия төрен исәпләп чыгарып, ярдәм итәрләр, элемтәгә керерләр дип өметләник.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Билет өчен акча кире кайтарыламы?

Россиянең көньягына аэропортлар эшен вакытлыча туктатты дигән хәбәрләр таралды. Билет өчен түләгән акчаны кире кайтарып буламы?

Исемем редакция өчен генә

Роспотребнадзор аңлатмасы
Моңа бәйле сораулар белән төбәктәге идарәгә аңлатма сорап мөрәҗәгать итәргә була. Рейс гамәлдән чыгарылган яки тоткарланган, маршрут үзгәргән яки рейс башкарылмаган очракта, пассажир юл өчен түләнгән сумманы кире кайтару хокукына ия. Россиянең көньягындагы кайбер аэропортларның эше 24 февральдән туктатылып торуын, шулай ук авиакомпанияләр очышларны башкара алмаска мөмкинлеген исәпкә алып, гамәлдән чыгарылган рейс пассажирлары билет өчен акчаны кире кайтара яисә очыш өчен башка вакытны сайлый ала. Консультация үзәгенә **+7(843)221-90-16** телефоны буенча мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Шулай ук Роспотребнадзорның Татарстандагы идарәсенең **+7(843)238-35-09** телефоны буенча да сораулар кабул ителә.

Светофор кирәк!

«Салават күпере – 2» торак комплексындагы 189 нчы гимназия («Заман») янында светофор юк. Балаларга юлны чыгарга бик куркыныч. Җәй айларында бөтенләй борчылабыз, чөнки аларның күпчелеге юлны самокатлар белән чыга. Светофор кайчан куярлар икән?

ГӨЛНАЗ. Казан

Казан мэриясе аңлатмасы
Урамның бу бүлемтегә юл хәрәкәтен оештыру буенча ГОСТ 32944-2014 таләпләренә туры килә. Проектта светофор урнаштыру каралмаган. Юл хәрәкәте иминлеге өчен монда ясалма тигезсезлекләр урнаштырылган, тизлек режимы сәгатенә 40 чакрымга кадәр чикләнгән. Өстәп шуны әйтәбез: башкалада светофор объектлары республиканың максатчан программалары кысасында урнаштырыла. «Салават күпере» микрорайонында яшәүчеләрдән килгән мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып, Казан шәһәре Башкарма комитеты әлеге юл бүлемтегенә светофор кую мәсьәләсен республика программаларының берсенә кертү мөмкинлеген караячак.

Акчаны кире бирмәде

Унар литрлы савытларга суны махсус автоматлардан алабыз. Ничәнче көн чыгам, кәгазь акча белән түлим, ә автомат «сдача» кайтармый. Әллә ничә сум җыелды инде. «Сдача» бирелми дигән кисәтү дә язылмаган иде. Акчаны кире бирмәсә, нишләргә?

РАИЛӘ. Казан

Редакциядән: су бирә торган автоматларда һәрвакыт техник һәм башка сораулар белән мөрәҗәгать итү өчен телефон номеры күрсәтелә. Шалтыратып, хәлне аңлатып карарга мөмкин. Шулай ук Роспотребнадзор идарәсенә хәбәр итәргә була. Бәлки, сезнең йортта шундый ук хәлдә калучылар бер сез генә түгелдер?

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА
әзерләде

ФИКЕР

Кайда гаделлек?

Халыкка беркайчан да җиңел булмады. Урамнарны төзекләндерү, су белән тәэмин итү, район үзәгенә бару-кайту өчен транспорт булмау… Соңгы елларда мәктәпләрне ябу турында хатлар газета битләрендә дә басылып тора. Сайлаган депутатларыбыз халык мәнфәгатьләрен күбрәк кайгыртсын иде.

Ихтирам белән,
Сәгъдулла ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ

Ярдәм көтәргәме?

Без гел ярдәмчел булдык. Әмма сугыш чоры балаларына ярдәм итмиләр. Без бит әле күп. Бу сорау кайчан хәл ителер инде…

Казаннан шалтыратучы

Редакциядән. Хөрмәтле укучыларыбыз! Бу сорауны без еш кабул итәбез, ишетәбез. «Халык авазы»на да шул зар белән шалтыратучылар күп килә. Мөрәҗәгатькә бәйле үзгәрешләр булса, һичшиксез, газета битендә аны язып чыгачакбыз, сез бу хакта беренчеләрдән булып беләчәксез.

УКУЧЫ СҮЗЕ

***

Риман Гыйлемхановның мәкаләләрен бик яратып укыйм. Күпме гыйлем алабыз! Фамилиясе дә бит гыйлем дигән сүздән башлана.

Илсөяр ЯРУЛЛИНА

ИЛТӨЗӘР МӨХӘММӘТГАЛИЕВ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘГӘ КАЙТАВАЗ

Минзәләбашлылар үзенчәлекле, белемле кешеләр алар, Адлер Тимергалин да шуннан бит. Ә «Хөршидә – Мөршидә»гә килгәндә, халык туймады аннан, җитми калды ул, һаман искә алабыз юксынып. Илтөзәр, афәрин, бар эшләрең дә уңышлы булсын!

Розалия САЛИХОВА

**35 ЕЛ СЫҢАР КУЛ БЕЛӘН ЯШӘҮЧЕ
МӘСХҮТ ШАКИРОВ ТУРЫНДАГЫ ЯЗМАГА КАЙТАВАЗ**

Мәсхүт абый турындагы язманы укыгач, сокланып, гаҗәпләнеп утырдым. Язмыш сынавын «шулай язылгандыр инде» дип кабул итеп, авырлыкларга бирешмичә, тормышын сокланырлык итеп үткән! Мәсхүт абыйга хөрмәтем бик зур. Арабызда батыр йөрәкле, нык кешеләр яшәвенә бик шат мин!

Кәүсәрия ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА

**ФИГУРАЛЫ ШУУЧЫ
КАМИЛӘ ВӘЛИЕВА ТУРЫНДАГЫ ЯЗМАГА КАЙТАВАЗ**

Камилә, синең бу батырлыгыңны мин сугыш вакытында дошманның ут чәчеп, атып торучы пулеметын үз күкрәге белән каплаган Александр Матросов, Газинур Гафиятуллин батырлыгы белән тиңлим. Син үзеңне горур йөртергә тиеш! Билгеле, син бүләккә лаеклы. Казандагы фигуралы шуу мәктәбенә дә синең исемне бирергә кирәк!

Илсур КӘРИМУЛЛИН

***

Аның күз яшьләре бозны гына түгел, безнең йөрәкләребезне дә өтте. Җирдә ятмас алар! Исән булсын, рухы сынмасын, киләчәктә әллә нинди үрләр яуларга насыйп булсын! Шулкадәр халыкның теләктәшлеге, мәхәббәте көч өстәсен аңа. Безнең өчен Камилә – чемпион, иң югары пробалы алтынга тиң ул!

Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА

7 март | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00 IX «Болгар радиосы» Милли музыка премиясен тапшыру тантанасы 6+
13.00 «Семь дней» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.30 «Туган җир» 12+
15.00 «ӘНИЕМНЕҢ ҖЫЛЫ КОЧАГЫ» 6+
17.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
17.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Мин» 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Соотечественники». Резеда Ахиярова. Музыка звезды 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «ЛЮБОВЬ НЕ ПО РАЗМЕРУ» 16+
00.00 «Син минем тиң ярым…» Зинира һәм Ризат Рамазановлар концерты 6+
01.35 «Семь дней+» Эльмира Калимуллина. Певица, заслуженная артистка Республики Татарстан 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Манзара» 6+
08.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
08.40 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 18.20 «ӘНИЕМНЕҢ ҖЫЛЫ КОЧАГЫ». Музыкаль телефильм 6+
12.05 «КАЙДА СИН?» 12+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 З. Хәким. «ИСКӘН ҖИЛЛӘР КӨЕНӘ». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
00.15 «Шаян хәлләр» 12+
01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
04.15 «Башваткыч» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.25 Фильм. «КАРНАВАЛ» 0+
06.00 Новости
06.10 «Карнавал» 0+
08.25 Андрей Миронов. «БУДЬТЕ МОИМ МУЖЕМ» 12+
10.00, 12.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других» (S) 12+
11.15, 12.15 «Видели видео?» 0+
14.05 «Порезанное кино» 16+
15.15 К 100-летию со дня рождения Евгения Матвеева. Фильм «ЛЮБОВЬ ЗЕМНАЯ» 12+
17.05 Кино в цвете. «ВЕСНА НА ЗАРЕЧНОЙ УЛИЦЕ» 12+
18.55 Премьера. Юбилейный концерт Олега Газманова (S) 12+
21.00 «Время»
21.20 «Голос. Дети». Новый сезон (S) 0+
22.55 Премьера. Икона стиля в док. фильме «МЭРИ КУАНТ» (S) 16+
00.40 «Андрей Миронов. Скользить по краю» 12+
01.35 «Наедине со всеми» 16+
02.20 «Модный приговор» 0+
03.10 «Давай поженимся!» 16+

РОССИЯ 1

05.25 Анна Тараторкина, Антон Филипенко, Алексей Шутов. «НЕВЕЗУЧАЯ» 12+
07.05 Елена Великанова, Андрей Чернышов, Екатерина Васильева, Роман Полянский, Игорь Ясулович, Александр Яцко. «ЖЕНИХ ДЛЯ ДУРОЧКИ». 12+
11.00, 14.00, 20.00 Вести
11.30 Ирина Гринёва, Игорь Верник. «МАМА ПОНЕВОЛЕ» 12+
14.30 Валерия Бурдужа, Денис Васильев, Юрий Батурин. «САМАЯ ЛЮБИМАЯ» 12+
16.55 «МОСКВА СЛЕЗАМ НЕ ВЕРИТ» 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Глафира Тарханова, Сергей Горобченко, Кирилл Гребенщиков, Татьяна Сытова. «Я ВСЁ НАЧНУ СНАЧАЛА» 12+
01.30 «ЖЕНЩИНЫ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 07.10, 04.25 XIII Зимние Паралимпийские игры. Прямая трансляция
07.00, 08.55, 09.25, 12.30, 21.50 Новости
09.00, 13.25, 16.00, 18.30, 00.30 Все на Матч! Прямой эфир
09.30 XIII Зимние Паралимпийские игры. Кёрлинг. Россия – Словакия. Прямая трансляция
11.30 Зимние виды спорта. Обзор 0+
12.35, 01.10 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. Обзор 0+
13.55 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. «Краснодар» – «Урал» (Екатеринбург). Прямая трансляция
16.25 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. «Ростов» (Ростов-на-Дону) – «Сочи». Прямая трансляция
18.55 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. «Ахмат» (Грозный) – «Рубин» (Казань). Прямая трансляция
21.00 «Громко»
21.55 Тотальный футбол 12+
22.25 Футбол. Кубок Англии. 1/8 финала. «Ноттингем Форест» – «Хаддерсфилд». Прямая трансляция
01.55 «Наши иностранцы» 0+
02.25 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Автодор» (Саратов) – ЦСКА 0+
03.40 Новости 0+
03.45 «Громко» 12+

НТВ

05.40, 08.20 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СУДЬБЫ» 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 Сегодня
10.20 Максим Дрозд. «ЗАПОВЕДНЫЙ СПЕЦНАЗ» (S) 16+
16.20 Остросюжетный сериал «ЗАПОВЕДНЫЙ СПЕЦНАЗ» (S) 16+
20.00 «Маска». Новый сезон (S) 12+
23.30 «Основано на реальных событиях» (S) 16+
02.25 Их нравы (0+
02.45 Максим Аверин, Алексей Воробьев, Ксения Кутепова в остросюжетном сериале «ГАСТРОЛЕРЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «ВОЛШЕБНАЯ ЛАМПА АЛАДДИНА» 0+
07.05 «ПРИЕЗЖАЯ» 16+
09.10 «МЕЖДУ НЕБОМ И ЗЕМЛЁЙ» 16+
11.00 «ВСПОМНИТЬ СЕБЯ» 16+
15.00 «НЕ ХОЧУ ТЕБЯ ТЕРЯТЬ» 16+
19.00 «НЕПРЕКРАСНАЯ ЛЕДИ» 16+
23.00 «ПРИВИДЕНИЕ» 16+
01.30 «НЕУКРОТИМАЯ АНЖЕЛИКА» 16+
03.00 «ПРИЕЗЖАЯ» 16+
04.35 «Восточные жёны» 16+
05.20 «КОРОЛЕВСТВО КРИВЫХ ЗЕРКАЛ» 0+

ЗВЕЗДА

06.00, 08.15 «НЕБЕСНЫЕ ЛАСТОЧКИ» 12+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
08.50 «БЛАГОСЛОВИТЕ ЖЕНЩИНУ» 16+
13.15 «ДЕМИДОВЫ» 12+
16.35, 18.20 «ГРАФ МОНТЕ-КРИСТО» 16+
01.10 «ЖЕСТОКИЙ РОМАНС» 12+
03.35 «ЛЕТУЧАЯ МЫШЬ» 12+

8 март | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00 «СЕРДЦЕ ЖДЁТ ЛЮБВИ» 12+
11.00 Творческий вечер композитора Эльмира Низамова 6+
13.20 «Женщина года. Мужчина года. женский взгляд» 6+
15.00 «ӘНИЕМНЕҢ ҖЫЛЫ КОЧАГЫ» 6+
17.00 Хоккей. Кубок Гагарина. «Авангард» – «Ак барс». Прямая трансляция 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Ватандашлар». «Урманнан сызылган җыр». Зилә Сөнгатуллина 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «КИЛИМАНДЖАРА» 16+
23.30 «ПАРИЖ – МАНХЕТТЕН» 16+
00.50 «Видеоспорт» 12+
01.15 «Соотечественники». «Альбина Шагимуратова. Примадонна Востока и Запада» 12+
01.40 «Семь дней+» . Гузель Яхина. Писатель, лауреат премий «Большая книга» и «Ясная Поляна» 12+
02.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
08.40 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 И.Зәйниев. «ЛЮСТРА». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
12.05, 20.00 «ӘНИЕМНЕҢ ҖЫЛЫ КОЧАГЫ». Музыкаль телефильм 6+
15.00 «Әниләр һәм бәбиләр». Концерт 6+
17.00 Хоккей. Гагарин кубогы. Плей-Офф уеннары. «Авангард» (Омск) – «Ак барс» (Казан). Турыдан-туры трансляция 6+
19.30, 00.40 «Татарлар» 12+
21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
21.25 «Женщина года. Мужчина года. Женский взгляд» 6+
22.45 П.Коэльо. «АЛХИМИК». Г.Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театры спектакле 12+
00.15 «Шаян хәлләр» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.30 Фильм Александра Петрова. «МОЯ ЛЮБОВЬ» (S) 12+
06.00 Новости
06.10 Фильм. «НЕВЕРОЯТНЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ИТАЛЬЯНЦЕВ В РОССИИ» 0+
08.05 Фильм. «ТРИ ПЛЮС ДВА» 0+
10.00, 12.00 Новости (с субтитрами)
10.10 «Будьте счастливы всегда!» Праздничный концерт в Кремле (S) 12+
12.10 «Девчата». 60 лет знаменитой комедии 0+
14.00 Фильм. «КОРОЛЕВА БЕНЗОКОЛОНКИ» 0+
15.30 Праздничный концерт «Объяснение в любви» (S) 12+
17.05 Фильм. «БРИЛЛИАНТОВАЯ РУКА» 0+
19.00 Фильм. «ЛЮБОВЬ И ГОЛУБИ» 12+
21.00 «Время»
21.20 Фильм. «КРАСОТКА» (S) 16+
23.35 Истории от первого лица в док. фильме «ЖЕНЩИНА» (S) 18+
01.40 «Наедине со всеми» 16+
02.25 «Модный приговор» 0+
03.15 «Давай поженимся!» 16+
03.55 «Мужское/Женское» 16+

РОССИЯ 1

05.40 Марина Коняшкина, Алексей Демидов, Дарья Повереннова, Артём Ткаченко «ЗАВТРАК В ПОСТЕЛЬ» 12+
09.40, 11.30 Вера Алентова, Алексей Баталов, Ирина Муравьёва, Раиса Рязанова, Александр Фатюшин и Владимир Басов в фильме Владимира Меньшова «МОСКВА СЛЕЗАМ НЕ ВЕРИТ» 12+
11.00 Вести
13.05 Маргарита Симонова, Анна Исаева, Алиса Фрейндлих, Валентина Теличкина, Александр Домогаров. «БОЛЬШОЙ» 12+
17.00, 02.20 Алиса Фрейндлих, Андрей Мягков, Олег Басилашвили, Светлана Немоляева, Лия Ахеджакова Эльдара Рязанова. «СЛУЖЕБНЫЙ РОМАН» 0+
20.00 Вести
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Премьера. ПРЕМИИ «НИКА» И «ЗОЛОТОЙ ОРЁЛ». Фёдор Федотов, Соня Присс, Алексей Гуськов, Северия Янушаускайте, Кирилл Зайцев, Тимофей Трибунцев, Юрий Колокольников. «СЕРЕБРЯНЫЕ КОНЬКИ» 16+
00.00 Александр Петров, Аглая Тарасова, Мария Аронова, Надежда Михалкова. «ЛЁД 2» 6+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.55, 04.30 XIII Зимние Паралимпийские игры. Прямая трансляция
06.30, 08.25, 12.30, 19.20, 21.50 Новости
06.35, 08.30, 15.50, 21.55, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
06.55 XIII Зимние Паралимпийские игры. Биатлон. Прямая трансляция
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.35, 03.50 Специальный репортаж 12+
12.55 «МатчБол» 12+
13.25 Хоккей. КХЛ. 1/4 финала конференции «Восток». «Сибирь» (Новосибирская область) – «Салават Юлаев» (Уфа). Прямая трансляция
16.30 Хоккей. КХЛ. 1/4 финала конференции «Восток». «Авангард» (Омск) – «Ак барс» (Казань). Прямая трансляция
19.25 Смешанные единоборства. Женские бои в UFC. Лучшее 16+
22.45 Футбол. Лига чемпионов. 1/8 финала. «Ливерпуль» (Англия) – «Интер» (Италия). Прямая трансляция
01.55 Футбол. Лига чемпионов. 1/8 финала. «Бавария» (Германия) – «Зальцбург» (Австрия) 0+
03.45 Новости 0+
04.05 «Голевая неделя» 0+

НТВ

05.3, 07.35, 08.20 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СУДЬБЫ» 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 Сегодня
10.20, 16.20, 19.40 «ЗАПОВЕДНЫЙ СПЕЦНАЗ» (S) 16+
22.10 Премьера. «Все звезды для любимой». Праздничный концерт 12+
00.20 Кристина Бабушкина в фильме «Я – АНГИНА!» 16+
03.30 «ГАСТРОЛЕРЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «КОРОЛЕВСТВО КРИВЫХ ЗЕРКАЛ» 0+
06.35 «МОЛОДАЯ ЖЕНА» 16+
08.35 «ПРИВИДЕНИЕ» 16+
11.00 «О ЧЁМ НЕ РАССКАЖЕТ РЕКА» 16+
15.00 «КАК ИЗВЕСТИ ЛЮБОВНИЦУ ЗА 7 ДНЕЙ» 16+
19.00 «ПРИНЦЕССА ИЗ ГОРОШИНО» 16+
22.55 «МЕЖДУ НЕБОМ И ЗЕМЛЁЙ» 16+
00.55 «АНЖЕЛИКА И СУЛТАН» 16+
02.45 «Восточные жёны» 16+
05.10 «6 кадров» 16+
05.15 «МОЛОДАЯ ЖЕНА» 16+

ЗВЕЗДА

06.00 «Не факт!» 12+
06.25, 08.15 «ТРЕМБИТА» 12+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
08.30 «НЕБЕСНЫЙ ТИХОХОД» 12+
10.00, 13.15, 18.15 «МАРГАРИТА НАЗАРОВА» 16+
00.15 «ГРАФ МОНТЕ-КРИСТО» 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 7–13 МАРТ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Моңа кадәр күп көч куйсагыз да, нәтиҗәсе ташка үлчим кебек кенә тоела идеме? Тынычланыгыз: сезнең өчен хәзер чын мәгънәсендә зур мөмкинлекләр ачылырга тора. Бу атнада моңарчы үзегезне куркытып торган эшләргә кыю төстә тотыныгыз – менә дигән нәтиҗәләргә ирешәчәксез.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Серлерәк атна. Килеп туган хәлләрне аңлау өчен эчке сиземләвегезгә бик нык таянырга туры килер. Ә инде эштә бер мәсьәләне хәл иткәндә яшерен сыйфатларыгызның шалт итеп кенә калкып чыгуы хәтта борыннарын бик хәтәр чөеп йөрүчеләрне дә берара сүзсез калдырыр.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Акчаны саклап тотыгыз, юкса бик кирәк чагында янчыгыгыз буш булып чыгарга мөмкин. Күңелегезне тынгысызлап торган бер мәсьәләгә ачыклык кертелер. Сез хәзер кысылган пружина кебек. Бераз иркенәегез – тормыш тәмен шундук яңача сизә башлаячаксыз!

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Җилдән килгән җилгә китәр. Менә шулай… Әмма моңа бетеренәсе түгел: тиздән сөенеп туймаслык керем чыганаклары барлыкка киләчәк. Бернигә карамастан!..

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Һәр нәрсәнең төбенә төшенүчән, аек акыллы, сизгер һәм зирәк булуыгыз эштә искитмәле уңышка ирешү мөмкинлеге бирер. Бу абруегызны гына түгел, акчагызны да арттырыр. Яңа танышыгыздан ишетелгән бер яңалык күңелегезне җилкетеп куяр.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
«Дүшәмбе – авыр көн». Әмма сезнең өчен түгел! Нәкъ менә атнаның беренче көнендә, тулы көчегезгә эшләп, үзегездән дә, эш нәтиҗәсеннән дә бик-бик канәгать калырсыз. Атна ахырында тормышыгызны тагы да ямьләндереп җибәрердәй хәлләр көтегез.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Карьера баскычыннан өскәрәк менеп китәм генә дигәндә, бер каршылыкка очрарсыз. Аны юкка чыгару өчен бераз уйланырга кирәк булыр. Ерактан килгән бер яхшы хәбәр сөендерер.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Шундый чор җитте – мөһим эшләрегезне инде башка кичектерергә ярамастыр. Курыкмагыз: аларны бик шәп итеп башкарып кую мөмкинлеге үзеннән-үзе диярлек килеп чыгар. Тик атна ахырында сәламәтлек кенә үзен бераз сиздереп алмагае.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Ашыгуны таләп итмәгән, бик тыныч атна. Тик шунысы бар: барлык эшләрегез җиңел бирелсә дә, иксез-чиксез кебек тоелыр. Балаларыгыз матур яңалыклары белән куандырыр.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Бу атнада беравык туктап калып, бүгенге тормышыгыз, киләчәгегез турында уйланып алу зыянга булмас. Юкса бертуктаусыз эшләп, уйсыз-хиссез «робот»ка әйләнеп барасыз кебек… Атна уртасында күңелегез теләгән хәбәр ишетерсез.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Акыл сәләтегез гадәттәгедән яхшырак сезнең хәзер! Хәтта инде күптәннән онытылган әйберләрне дә искә төшерәчәксез. Башыгызда яшен тизлегендә бик шәп планнар барлыкка киләчәк. Аларны шундук тормышка ашырудан курыкмагыз – тәвәккәллек үзен тулысынча аклаячак!

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Күңелегезне юмартлык, мәрхәмәтлелек хисе биләп алыр. Бу кемгәдер ярдәм кулы сузу, игелек эшләү теләге уятыр. Атна ахырында кучемсез милеккә бәйле бер проблемагызга ачыклык кертелер.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе, элекке КПСС Сарман районы беренче секретаре, «Татмелиорация» траст компаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенең эксплуатация бүлеге элекке җитәкчесе

Әсгат Харис улы Әхмәтшинның

кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

КӘЕФ ТӘ ВИТАМИНГА БӘЙЛЕ

pixabay.com

Тән тиресе бозыла, чәч коела, нindидер ят ризык ашыйсы, көн дәвамында йоклыйсы килә... Күптән көтелгән язны еш кына әнә шундый сүлпән каршылау кәефне кыра. Барыбызга да яхшы таныш авитаминоз галәмәте бу! Бүгенге сәхифәдә авитаминоз турында аеруча еш ишетергә туры килгән уйдырмаларны барлап, белгечләрнең аңлатмаларын тупладык.

1 нче уйдырма. Даими рәвештә йокы килү, арыганлык бетмәү, чәч коелу, тырнак сыну организмга витаминнар җитмәү турында кисәтә. Дөрестән дә, авитаминозның төп билгеләре бу. Әмма бу билгеләр организмдагы башка хилафлыклар турында да кисәтә ала. Әйтик, кеше гемоглобины түбән булганда – анемия вакытында да үзендә шундый үзгәрешләр сизәргә мөмкин. Организмга B_{12} витамины, фолий кислотасы җитмәгәндә дә йокымсырау, арыганлык, чәч коелу кебек күренешләр борчый ала.

2 нче уйдырма. Авитаминозны витаминнар ярдәмендә генә җиңеп була. Кеше дөрес тукланмаса, аңа витаминнар да ярдәм итмәячәк. Шуңа күрә көндәлек рационда һәрчак яшелчә, җиләк-җимеш, боткалар, чикләвек, балык кебек ризыклар булырга тиеш. Яз көне аларга аеруча басым ясарга кирәк. Иттән баш тартырга ярамый. Аны атнага ким дигәндә ике тапкыр ашарга кирәк. Дөрес тукланган кешедә авитаминоз бик сирәк күзәтелә.

3 нче уйдырма. Авитаминоз яз һәм көз көннәрендә генә күзәтелә. Организм витаминнарга ел дәвамында кытлык кичерергә мөмкин. Хәтта яшелчә, җиләк-җимеш мул булган, Д витаминына бай кояш нурлары сирпегән җәй көнендә дә авитаминоздан интегүчеләр бар. Әмма язын организм «уянгандай» була: матдәләр алмашы тизләнә, нәтиҗәдә витаминнарга кытлык та бу чорда яхшырак сизелә башлый.

4 нче уйдырма. Кыш буе кибетләрдә сатылган яшелчә һәм җиләк-җимешләрнең бер файдасы да юк. Озак саклансын өчен махсус ысуллар ярдәмендә эшкәртелсә дә, кибеттә сатылган яшелчә һәм җиләк-җимешләрдә дә витаминнар җитәрлек була. Көнөнә йодрык кадәр зурлыкта биш төрле яшелчә яки җиләк-җимеш ашасагыз, сезгә авитаминоз куркыныч түгел дигән сүз. Сүз уңаеннан, файдалы элемент һәм витаминнарны башка төр ризыклардан да алып була. Әйтик, сыер маенда, бавыр, йомырка, сырда А витамины күп, ипи, тары, карабодай, солы ярмалары В витаминына бай.

КАЙСЫ ҖИТМИ?

ВИТАМИН ТӨРЕ	НИНДИ БИЛГЕЛӘР КҮЗӘТЕЛӘ?	КАЙДАН ТАБАРГА?
А витамины	күз күрүе начарлана, күз кабагы кычыта, тән кытыршылана, чәч төсе тоныклана, тешләр саргая	сөт ризыклары, диңгез ризыклары, карлыган, крыжовник, абрикос, кишер, шпинат
B_1 витамины	тән тиресе сула, тын кысыла, аппетит начарлана, аритмия	чүпрә, камыр ризыклары
С витамины	теш казналыгы каный, кариес пәйда була, сулыш алу кыенлаша, ашкайнату системасы начар эшли башлый, хәлсезлек сизелә, кеше тиз арый башлый	яшелчә, җиләк-җимешләр, кара карлыган, томат, шпинат
D витамины	кариес пәйда була, буыннар авырта, тәнне көзән җыера, кеше ябыга	бавыр, йомырка, сөт ризыклары, майлы балык
Е витамины	организм тизрәк картая, тән тиресе «шиңә», күз күрүе начарлана	йомырка, кәбестә, шпинат, кишер, зәйтүн мае, җитен мае, миләш, сыраганак, балык мае, чикләвек
К витамины	тән тиресе аз гына җәрәхәтләнсә дә бик нык кан киту, теш казналыклары канау, ашкайнату системасы бозылу, хәлсезлек	кәбестә, брокколи, шпинат

Лилия БУЛАТОВА, табиб-терапевт:
– Авитаминоздан саклану өчен иң беренче чиратта дөрес тукланырга кирәк. Моның өчен табында аксымга бай ризыклар (балык, йомырка, эремчек һ.б.), яшелчә һәм җиләк-җимеш булу шарт. Начар гадәтләрдән баш тартып, сәламәт тормыш алып бару, көн дәвамында саф һавада йөрү дә файдага булачак. Организмны борчыган барлык авыруларны да җиренә җиткереп, ахыргача дәваларга кирәк. Дәваланып бетмәгән чир шулай ук витаминнар кытлыгы китереп чыгара ала. Язгы-көзге чорда, профилактика максатыннан һәркемгә витаминнар эчеп алырга киңәш итәр идем. Балаларга, яшүсмерләргә, йөкле һәм имезүче хатын-кызларга, өлкәннәргә ул бигрәк тә файдага булачак. Язгы чорда бигрәк тә А, С, D витаминнары эчәргә киңәш ителә. Авитаминоз чорында көнөнә икешәр капсула D витамины, балык мае эчү дә ярдәм итәчәк.

Гөлчирә НӘҖМЕТДИНОВА, үләннәр белән дәвалаучы (Арча районы Наласа авылы):
– Язгы хәлсезлектән гөлҗимеш, кычыткан, тукранбаш төнәтмәсе эчәргә була. Суган, сарымсак ашау, балан суы эчү дә файдалы. Витамин җитмәүдән чәч сынса яки коела башласа, чәчне югач, төбенә кычыткан суы тидерү дә шифалы. Иммунитетны ныгыта торган төнәтмәләр дә эчсәң була. Ләкин анысын яз җитеп, эш узгач түгел, ә көздән эчә башларга кирәк. Андый төнәтмәләрне үзебездә үсмәгән үләннәрне читтән алдырып, бездәгеләре белән кушып ясыйм. Организмны витаминнарга баета торган төнәтмәне исә һәркем ясый ала. Блендерда вакланган 10 тырнак сарымсакны бал белән кушып, суыткычта сакларга киңәш итәм. Шуны көнгә 1 аш кашыгы кабып куярга кирәк.

Абау!

ШИКӘР БЕЛӘН ДУСЛЫК ӨЗЕЛСӘ...

Шикәрдән баш тарту депрессиядән коткара. Америка галимнәре шундый нәтиҗәгә килгән. «Күп шикәр ашау депрессия белән бәйле. Шуңа шикәрле ризыкларны мөмкин кадәр азрак ашаганда кешенең кәефе күтәрелә», – ди белгечләр. Галимнәр шикәрдән баш тартуның тагын нинди нәтиҗәләргә китергәнен ачыклау өчен махсус тикшеренү дә уздырган. Алар анда катнашучылардан рационнан шикәрле ризыкларны алып ташлаганнан соң үзгәрешләрне теркәвен сораган. Шул рәвешле белгечләр шикәрдән баш тартуның диабет, йөрәк-кан тамырлары, Альцгеймер авыруларын, артрит барлыкка килү ихтималын киметүен ачыклаган. Диетолог Элисон Таллман сүзләренә караганда, шикәр белән дуслыкның өзелүе яман шешнең кайбер төрләре барлыкка килү ихтималын да киметә.

Кан тамырларын ныгытабыз

Кан тамырлары тыгылса, баш миенә туклыклы матдәләр җитәрлек күләмдә килми. Баш мие тулы күәтенә эшләмәсә, ул бөтен организмда чагылыш таба. Шуңа да кан тамырларының сәламәтлеген иң беренче чиратта кайгыртырга кирәк.

Моның өчен:

✓ эчә торган чәегезгә көн дә бер генә чеметем дарчин – корица өстәгез. Атна-ун көннән соң нәтиҗәсе гаҗәпләндерәчәк. Болай эшләгәндә баш миенең уйлау-фикерләү сәләте күпкә арта;

✓ бер чегендернең согын сыгып, суыткычта 2–3 сәгать тотыгыз да, бал белән туглап, ашаганнан соң көнөнә 3 тапкыр 4 аш кашыгы йотып куегыз. Моны өч атна дәвамында эшләргә кирәк. Ике ай ял иткәч, янә кабатларга мөмкин. Нәтиҗәсе озак көттермәс;

✓ какао эчү дә баш миенең эшчәнлеген яхшырта. Аны бигрәк тә өлкән яшьтәгеләргә эчәргә киңәш ителә.

Кирәге чыгар

ДӘФНӘ ЯФРАГЫ БУЫННАРНЫ НЫГЫТА

Әлеге төнәтмәне ясау өчен, иң элек зурлыгына карап, 3–5 лавр яфрагын 300 мл суга салып, 5 минут кайнатырга кирәк. Кайнатканда савытның капкачын япмаска. Болай бөерләргә зыян салу ихтималы булган эфир майларының бер өлеше парга әйләнә. Аннан соң 4–5 сәгатькә төреп куярга яки термоста төнәтергә. Төнәтмәне 12 сәгать буе аз-азлап эчәргә кирәк. 3 көн эчкәч, бер атна тәнәфес ясарга һәм дәвалану курсын тагын кабатларга. Бу көннәрдә иттән баш тартыра кирәк. Лавр яфрагы төнәтмәсе буыннарны чистарта, тозларны чыгара, ди белгечләр.

Редакциядән: тискәре йогынтысы булырга мөмкин. Киңәшләрне кулланыр алдыннан табиб белән киңәшләшегез.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ЧӘЧКӘЛӘРНЕҢ – ҮЗ СЕРЕ

Халыкара хатын-кызлар көне алдыннан флорист Наилә ХӘСӘНОВА белән чәчәкләр турында сөйләштек.

:: Наилә ханым, 8 Мартка гадәттә лалә һәм мимоза бүләк итәләр. Әмма флористиканың үз кагыйдәләре бар. Әниләргә, хатын яки сөйгән кызыңа нинди чәчәк бүләк итү дөресрәк?

– Флористика кагыйдәләре буенча, ир кеше үзенең әнисенә, аның мөһимлеген, бөеклеген, чиксез яратуын белдереп, лалә, хризантема яки ромашкалардан торган чәчәк бәйләме бүләк итә ала. Шәмәхә төстәге лаләләрне дә әниләргә бүләк итү дөрес. Ә инде ир үзенең сөекле хатынына – мәхәббәт, дәрт һәм матурлык символы буларак, кызыл розалар, зәңгәрсу төстәге дельфиниумнар, кызына исә алсу розалар сайлап алса әйбәт. Егет кеше үзенең сөеклесенә пакьлек символы – ак розалар, лалә, гиацинт бәйләмнәре бүләк итсен. Бәйләмнең бер төрле генә чәчәкләрдән торуы әйбәт.

:: Чәчәкләр сайлаганда аның санының мөһим булуын да беләбез.

– Бәйләмдә чәчкәләрнең так санда булырга тиешлеге барыбызга да мәгълүм. Әмма чәчәк саны 12дән арткан очракта, ул 6га бүленергә тиеш. Шул ук вакытта беркайчан да 13 чәчәк бүләк ителми. Конкрет саннарның нәрсә аңлатуына килсәк, өч һәм биш чәчәк – ихтирам-хөрмәт, җиде – мәхәббәт, тугыз иксез-чиксез ярату билгесе булып тора.

:: Сары төстәге чәчәкләрне бүләк итәргә ярамый, диләр. Флористикада төсләр нинди мәгънәгә ия?

– Сары төс, күпләребез уйлаганча, аерылышуны түгел, ә дуслыкны, туганлыкны аңлата. Кояш төсендәге чәчәк бәйләмен егетләр һич шикләнмичә сөйгәннәренә бүләк итсеннәр. Телгә алып үтелмәгән башка төсләргә килсәк, алтынсу төс – байлык, зәңгәр һәм күк төсләр – тугрылык, яшел – өмет-ышаныч билгесе.

:: Чәчәк бәйләмен вазада озаграк шиңдермичә саклау ысулларын да әйтеп үтсәгез иде.

– Чәчәкләр озаграк шиңмичә саклансын өчен иң элек вазада суга тиеп торган яфракларын өзеп ташларга кирәк. Алар тиз чери башлый һәм чәчәккә зыян сала. Вазага салкынча су тутырыгыз. Сабак очларын ике-өч көнгә бер тапкыр кисеп торыгыз, суын да шул тәртиптә алыштырыгыз. Ә лаләләрне, гомумән, боз салынган суда тотарга кирәк. Шулай ук кар өстәргә дә була. Бу чәчәкләр, табигатьтә иң беренчеләрдән булып чәчәк атканлыктан, салкынны бик ярата.

8 Мартта хатын-кызларга иң еш бүләк ителә торган әйбер – чәчәк бәйләме. Бәйрәм алдыннан Сбер-Маркет һәм Viber мессенджеры үткәргән сораштыруда ир-атларның 68,8 проценты шушы бүләкне өстен күрүләрен әйткән. Татлы күчтәнәчләр (ирләрнең 32,9 проценты шуны сайлый), бизәнү-ясану әйберләре (30,6 процент), йомшак уенчыклар (22,6), көнкүреш товарлары (20,5) бүләк итүчеләр дә байтак. Иң кызыгы: сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, хатын-кызларның күңеле дә башлыча шушы бүләкләргә тартыла. Туташ-ханымнар арасында акча, сертификат, кием-салым бүләк итүләрен яратучылар да бар, ләкин алар бик күп түгел.

Аш-су

8 Март салаты

Римма ГАББАСОВА рецепты

Кирәк булачак: *200 грамм краб таякчыклары, 4–5 данә йомырка, 1 банка кукуруз, 1–2 чи яки тозлы кыяр, бер бәйләм яшел суган, яфраклы салат, бизәү өчен укроп, тәменчә майонез.*

Кыярны, краб таякчыкларын – вак шакмакларга, яшел суганны гадәттәгечә турыйбыз. Кукуруз банкасын ачып, суын саркытабыз. Йомырканы пешереп, икесенең сарысын агыннан аерабыз һәм шакмаклап турыйбыз. Агын угыч аша уып, читкә куеп торабыз. Барысын бергә салып (йомырка агыннан башка), майонез өстибез һәм болгатабыз. Игътибар: майонезны күп салырга кирәкми. Юкса салат сыек булачак һәм формасын саклый алмаячак.

Шуннан зуррак сай тәлинкәгә салат яфракларын җәябез. Сигезле эчендәге түгәрәкләрне ясау өчен яфрак өстенә ике чәркә куябыз. Шулар тирәсенә, 8 саны рәвешенә китереп, салатны урнаштырабыз. Салат өстенә йомырка сарысын угычтан уып сибәбез, нәзек кенә укроп яфраклары белән бизибез. Чәркәләрне алабыз. Шулардан калган түгәрәкләр эченә йомырка сарысын (угычтан уып) тутырабыз. Салат тирәсен үзебезгә ничек кирәк, шулай бизибез.

Сорау – җавап

Сорауларга бакчачы-блогер Эльмира ИСХАКОВА җавап бирә

АЛМАГАЧНЫ КУЯН КИМЕРСӘ...

– Яшь алмагачның кайрысын куян кимергән. Агачтагы мондый яраларны ак, зәңгәр, яшел лак белән буяп «төзәтергә» мөмкин, дип ишеткән идем. Бу дөресме?

Наилә ЗАРИПОВА. Казан

– Кәүсә әйләнәсенә тулысынча зыян килсә, агач корыячак. Кимерү эзе бер урында гына булса, төзәлә. Лак дигәннән, әле суык, кубып төшәчәк. Бу очракта сезнең агачка «садовый вар» сыларга кирәк. Башта кәүсәдәге яраны марганцовкалы су белән юып алыгыз. «Садовый вар» сылаганнан соң, өстен чүпрәк белән бәйләп куегыз. Ләкин ачык җире калмасын. Бөреләр уянгач, чүпрәкне чишеп, «дару»ны аңадан сыларга мөмкин. Болай эшләгәндә, агач суты йөри башлаганчы, яра шактый ук төзәләчәк. Ә инде бөтенләй төзәлгәч, чүпрәген алып ташлагыз.

КАЙСЫ СОРТЛАР ЯХШЫРАК?

– Ачык һавага утырту өчен кыска сабаклы помидор сортларының кайсылары әйбәтрәк?

Лилия КӘРИМУЛЛИНА. Балык Бистәсе

– Кыска сабаклы («карликовый») сортлардан безнең якларда «Челнок», «Настенька», «Китайский ранний», «Розовый агат», «Санька», «Данко», «Лентяйка», «Агата», «Монгольский карлик», «Ямал», «Вельможа», «Супермодель» кебек сортлар яхшы үсә. Алар тәбәнәк кенә, уңышны мулдан бирә, «үги» яфраклары да күп чыкмый. Ләкин араларын киңрәк калдырып утырту әйбәт.

Исеңдә тот!

Чәч майланмасын дисәң...

Яз җитүгә карамастан, баш киеме салырга иртәрәк әле. Ә башлык, капюшон астында чәчләр тиз майлана. Баш тиресендәге май бизләре эшчәнлеген «тәртип»кә салу өчен, төнәтмә ясап, шуны чәч төбенә сөртергә мөмкин. Төнәтмә болай ясала. Ярты литрлы шешәгә чыршы яки нарат ылысы тутырып, ылыс күмелгәнче, аракы салабыз. Шешәне 2–3 атна дәвамында караңгы урында тоткач, сөзәбез. Төнәтмәгә бераз чәй агачы, артыш яки эвкалипт мае тамызабыз (100 мл суга 5–6 тамчы). Шуны һәр көн саен чәч тамырларына сөртәбез. Болай эшләгәндә, чәч тиз майланмаячак, күпереп торачак. Төнәтмә шулай ук чәч тамырларын сихәтләндереп, ныгытып җибәрә.

Белеп тор!

ВАКЫТЫ ЧЫКМАГАНМЫ?

Гадәттә, без – хатын-кызлар ниндидер крем банкасы ачсак, беткәнче, шуны сөртәбез. Әмма аларның һәркайсының саклау вакыты бар. Ул тюбик яки банкада күрсәтелә. Кремны ачуга, саклау вакыты кими башлый. Аны ачык килеш күпме саклап булуын тышында капкачы ачылган банка рәвешендәге билгесеннән күрергә мөмкин. Кояшта торганда, яраклылык вакыты тагын да тизрәк чыгачак.

Бу кагыйдә башка косметика әйберләренә дә кагыла. Әйтик, ачылган тушьны 2 айдан кубрәк саклап булмый. Шушы вакыттан соң ул кибә, төерләнә. Иннек тә шулай: ике айдан соң иреннәргә начар сылана башлый, исе үзгәрә. Ә менә иннектәге су тамчыларыннан шикләнергә кирәкми. Бу аның кимчелеге түгел, ә, киресенчә, өстенлеге булып тора. Гадәттә балавыздан эшләнгән сыйфатлы иннек тамчылана.

Коры косметика («румяна», сөрмә, кершән) алай тиз бозылмый. Алар пумалага йокмый башласа, аның өске катламын алырга кирәк. Иң гади ысулы – скотч ябыштырасың да куптарасың. Бизәнү әйбере шундук элекке хәленә кайтачак.

Валентина СЕМЁНОВА әзерләде

ИРГӘ ДӘ, ИЛГӘ ДӘ – ТЕРӘК

Яхшы кием – туй дәүләте, яхшы хатын – өй дәүләте, дигән борынгылар. Асыл зат булудан тыш, хатын-кызга җәмгыятьтә, гаиләдә дә бик күп вазыйфаларны үз өстенә алырга туры килә. Хәзерге заманда, гомумән, бар нәрсәнең токтасы да, авызлыгы да хатын-кызда дип әйтү арттыру булмас.

Сәхифәбез кунагы – «Тәүбә» мәчетеннән Артур хәзрәт ГАБДУЛЛИН белән хатын-кыз хакы, җәмгыятьтәге урыны, хокуклары турында сөйләштек.

:: Хәзер хатын-кызлар машина да йөрли, җитәкче урыннарны да били, сәясәт белән дә кызыксына, бизнес белән дә мавыга. Пәйгамбәребез (с.г.в.) чорында андый хатын-кызлар булганмы?

– Хәзерге заманда хатын-кызлар игътибар үзәгендә булырга тырыша. Бу төрле өлкәләрдә күренә. Хатын-кыз – бөтен җирдә. Һәр өченче машинаның рулен дә хатын-кыз тота! Артка борылып, әби-бабаларыбызның тормыш, көнкүрешен карасак, аларның тыйнак яшәгәненә игътибар итәрбез. Хатын-кызларның киенү рәвешен генә алыйк. Тыйнак булып, оялып кына көн ителгән. Гасырлар узды, гүзәл зат та үзгәрде, кызганыч, тыйнаклык, оят онытылып бара. Хатын-кыз белән ир-атның рольләре алмашына диярлек була. Пәйгамбәребез (с.г.в.) чорында мондый хәлләр булса да, сирәк очраган. Аның хатыны Хәдичәне генә алыйк. Алар өйләнешкәндә пәйгамбәребез (с.г.в.) 25 яшьлек, Хәдичәгә 40 яшь була. Хәдичәнең бик дәрәҗәле хатын-кыз, тол булуы, аның сату-алуга бәйле шөгыле барлыгы билгеле. Әлбәттә, барлык хатын-кызларда да мондый мавыгулар булмаган. Мәккә шәһәрендә ул чакта гүзәл затларның игътибар үзәгендә булуы күзәтелми. Киресенчә, ул вакыттагы хатын-кызлар чит ирнең аларга карагылуына да юл куймаган. Алар өчен бу бик куркыныч гөнаһ саналган. Сәясәт, җитәкчелек итү кебек эшләрдә хатын-кыз катнашмаган. Аллаһы Тәгалә ир-атның да, хатын-кызның да бурыч-вазыйфаларын билгеләгән бит инде. Икесе дә үз урыннарын белгәндә, гаилә камил була.

:: Диндә хатын-кыз хакы турында ни диелә?

– Берәр сорау туса, халык хәзер аңа җавапны интернеттан карый. Ислам диненең хатын-кызга булган карашын да күпчелек очракта интернет-пропаганда аша беләләр. Гомумән, социаль челтәрләрдә, телевидениедә һәм башка чыганакларда ислам динендә хатын-кызның бер хакы да юк, ул гел түбәнсетелә, дигән фикерләр йөри. Шушы сүзләр иң элек дингә яңа килгән, башка дин вәкилләренә бик нык тәэсир итә. Алар бит бу мәгълүматны тикшереп тормый. Ишетеләр дә, «әһә, димәк, хатын-кыз шундый, мөселман булырга кирәкми икән, интегеп яшәрсең», диләр. Ә бит асылда гүзәл затның диндәге хакы югары дәрәҗәдә. Коръәни Кәримдә «Ниса» дигән сүрә бар. Ул «Хатыннар» дип тәрҗемә ителә. Ә «Ирләр» дигәне юк. Изге китапның аерым бер өлеше хатын-кызларга багышланган. Аллаһы Тәгалә аларның дәрәҗәсе нинди булуын әнә шулай күрсәтә. Хатын-кызга гына бу дөньяга яңа кеше китерү мөмкинлеге бирелгән. Ул 9 ай буе йөрәге янында тере кешене йөртә, авырлык белән таба, тәрбияләп үстерә. Мондый сынаулар узган кеше ничек итеп динебездә кимсетелсен ди?! Икенчедән, пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисләре әни, апа, сеңел, хатыныбызга бик яхшы мөнәсәбәттә булырга өйрәтә. Сүзме, гамәл беләнме кимсетмәскә, зыян китермәскә өнди. Хәдисләрне укып караган кеше ислам динендә хатын-кызның дәрәҗәсе зур булуын аңлаячак. Хак динебездәге хатын-кызның тормышы – иң тыныч, матур, рәхәт тормышларның берсе.

:: Аллаһы Тәгаләнең ир кешене гаилә башлыгы һәм хатыннар өстеннән идарә итүче итеп билгеләве юкка гына түгелдер инде. Әмма хәзер киресенчә кебек...

– Гаиләдә баш булу дигән сүзне дөрес итеп кабул итәргә кирәк. Ир баш икән, бу әле аңа хатын-кызны кимсетү, рухи, физик яктан зыян китерүне хокук итеп бирми. Гаиләдә баш дигән сүз өй эчендә барлыкка килгән сынау-мәшәкатьләрне хәл итүне, үз өстенә алуны күздә тота. Ир-ат – гаиләне саклаучы, яклаучы, ризыкландыручы. Аның өстенә шушы вазыйфалар йөкләнгән. Хатын-кыз исә ир-атка терәк һәм ярдәмче булырга тиеш. Бу зат янында ир-ат үзен көчле итеп тойса хәерле. Хәзерге заманда рольләр алмашына. Интернет, телевидение аша пропаганда бара. Төрле юнәлешләр бар, мәсәлән, феминизм. Алар хатын-кыз бәйсезлеге өчен бар тырышалар. Бу – акылсыз кешеләр фикере. Хатын-кыз белән ир-ат аерым яши алмый, алар – бер-берсен тулыландыручы. Камил мөнәсәбәтләрдә икәү кирәк. Аллаһы Тәгалә аларны бер-берсе өчен бар иткән. Үзеңнән уйлап чыгарып, ниндидер яңа юнәлешләр булдырып, канунга каршы барырга ярамый. Ислам дине өйрәткәнчә яшәргә кирәк. Шушы агымнар тәэсирендә күп кенә хатын-кызлар ирләре өстеннән идарә итә, басып яши башлый. Күп кенә гаиләләрдә шундый хәлләр күзәтелә: хатыны иренә ягымлы итеп эндәшми, ир-ат җавап кайтармый, хатын-кыз сүзенә генә ияреп, ир-ат иткән сыйфатларын югалта, чүпрәккә әйләнә. Халыкта да юкка гына, ир – баш, хатын – муен, диелми. Баш кай якка борылса, муен да шул юнәлешне ала.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Еш кына хатын-кызлар гаиләдә җәбер-золым күреп яши. Балалар дип түзә. Кеше сүзеннән дә курку бардыр, шуңа аерылмый. Бу очракта хатын-кызга түзеп яшәү урынына иреннән китү хәерлерәк түгелме?

– Бу мәсьәләдә һәр очракны индивидуаль карарга кирәк. Һәр гаиләдә хәл төрлечә. Бу гаилә яшәгән төбәктә казый булса, мәсьәләне аның белән хәл итү хәерле. Мөселман гаиләсендә хатын-кыз иреннән җәбер-золым күрә икән, түзәргә тиеш, дип беркайда да язылмаган. Кеше сүзеннән курку бөтенләй дөрес түгел. Мең кеше булса, мең төрле фикер була. Аллаһы Тәгаләгә ярарга тырышырга кирәк.

:: Шулай итеп, хатын-кызны бизи торган сыйфатлар – ул...

– Иң элек – тыйнаклык, оятлы булу, иренә буйсыну. Әлбәттә, Аллаһы Тәгалә тарафыннан рөхсәт ителгән гамәлләргә буйсыну турында сүз бара. Аннан килеп, ярдәмчел, иренә терәк, юл куя белү хатын-кызны бизи. Ир-ат бер көнне шундый кәефле, икенче көнне башкача булырга мөмкин. Хатын-кыз гына аңа юлны таба белә, ул гына – ир-атка тәэсир итә торган зат. Халык: «Ирне ир дә, юк та иткән – хатын», – ди. Ир-атның нинди булуы сездән тора.

Гыйбрәт ал!

«Миннән олырак кешеләр дә бар икән!»

Элек заманнарда бер солтан, киек җанвар аулап, сараена кайтырга кичкә кала һәм авыл читендәге йортта кунача кала. Билгеле, солтанны кадерләп каршы алалар, иң яхшы урын-җирне җәеп бирәләр, сый-хөрмәт күрсәтәләр. Хаким кеше дә хуҗалардан бик канәгать кала.

Менә берзаман төнлә йорт хуҗаларының сабыйлары елап уяна. Йорт эчендә күпме халык бар, бөтенесе дә ошбу баланың көен көйләп йөгерешә. Хәтта ки солтанның өйдә барлыгын да онытталар.

Бала тынычланганчы, аны кулдан-кулга йөртәләр, кадерле кунакны исләренә төшереп караучы да булмый.

– Ә, менә бит, болай да була икән, – дип уйлана солтан. – Моңа кадәр мин

үземне иң олы дәрәҗәдәге кеше дип белә идем бит. Алай түгел икән! Миннән дә олырак кешеләр бар икән дөньяда. Хәзер исә ул – бишектәге сабый.

Йәгез, бер дога!

Мәчеткә кергәндә укыла

«Аллаһуммә-фтәх лии әб-үәәбә рахмәтикә вәншур гәләййә хазәәинә рахмәтик».

Мәгънәсе: «Йә, Раббым, миңа Рәхмәт ишекләреңне ач һәм Рәхмәт хәзинәләреңне чәч».

Мәчеттән чыкканда укыла

«Аллаһуммә иннии әс'әлүкә мин фәдъликәл-гәзыйм».

Мәгънәсе: «Йә, Раббым, дөреслектә, мин Синнән олуг фазыйләт һәм Рәхмәтеңне сорыйм».

kzn.ru

Өч хәдис

✓«Адәм баласына сабырлыктан да зуррак байлык бирелмәде».

✓«Көчле мөселман көчсез мөселманга караганда Аллаһка сөйкемле, ләкин икесендә дә хәер бар».

✓«Кешеләрнең иң көчсезе – дога да кыла алмаганы, ә иң сараны – сәлам дә бирә алмаганы».

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

НАЗ БӘЙРӘМЕ

Язга аяк бастык. Гүзәллек, мәхәббәт һәм җылылык бәйрәменә кадәр аз гына вакыт калып бара. 8 Март – Халыкара хатын-кызлар көне алдыннан «Ни хәл?» сәхифәсе кунаклары белән танылган гүзәл затларыбыз турында сөйләштек.

ВИЛДАН ШӘМСЕТДИНОВ: «ХАТЫНЫМНЫҢ НАЧАР СЫЙФАТЛАРЫ ЮК»

Яшьрәк чакта өйләнү турында, гомумән, уйлап та карамадым. Башымда идеаль хатын-кыз образы да юк иде. Гөлназны очраткач та, бу кыз миннән башка берәүгә дә эләгергә тиеш түгел, дигән уй күңелемә килде. Ул чакта аның сыйфатларын яхшыга һәм яманга аерып тормадым, ул мине шундук бар булмышы белән җәлеп итте һәм күңелдән китмәде. Бергә булуыбызга дүртенче ел киткән – вакыт шулкадәр тиз уза. Шушы еллар эчендә Гөлназның барлык сыйфатларына да гашыйк булдым. Барысын да аермыйча, бертигез хөрмәт итәм. Чөнки ул мөселманнарча тәрбияләнгән – начар сыйфатлары, гомумән, юк.

БУЛАТ БӘЙРӘМОВ: «ГОРУРЛЫГЫ БЕЛӘН ҖӘЛЕП ИТТЕ»

Һәр егет өчен идеаль хатын-кыз образы – ул әнисеӗер, миңа калса. Минем әни – бик итагатьле, акыллы, ипле, пөхтә, уңган. Башымда менә шундый образ булгандыр. Ләкин яшь чакта образга түгел, кешегә гашыйк буласың бит. Ләйсән белән тәүге тапкыр университетка укырга кергәндә очраштык. Башка кызлар көлешеп, елмаешып йөрсә, ул янымнан горур гына, игътибар да итмичә узып китте. Менә шул ягы белән җәлеп итте дә инде. Билгеле, тышкы матурлыгы, җырлавына да шундук гашыйк булдым. Ул өлгер, җитез, бер эшкә тотынса, минутында эшләп ташларга ярата. Чисталыгы, уңганлыгы, артык күп сөйләшергә яратмавы белән дә әсир итте Ләйсән. Мәкерле, ялганчы, ялагай кешеләрне яратмый ул, үзе эчендәгесен турыдан әйтә. Бу сыйфатларын аеруча хөрмәт итәм. Ләйсән – искиткеч әни. Балаларыбызга тиешле тәрбия бирә. Аларга: «Әтиегездән рөхсәт сорагыз», – дип кенә тора, мине ир буларак бик хөрмәт итә. Туганнарым белән дә җылы мөнәсәбәттә ул.

Яшь чактагы хисләр – башка инде ул. Озак еллар бергә яшәп, балалар үстереп, шактый сынаулар аша узганнан соң ир белән хатын арасындагы мәхәббәт хисе ныгый гына ул.

РИЗАТ РАМАЗАНОВ: «БЕЗНЕҢ КЕШЕ БУЛГАНЫ ӨЧЕН ЯРАТАМ»

Егет чагымда үземнең әни шикелле хатын-кыз белән кавышырга теләдем. Һәркем өчен үз әнисе һичнинди кимчелекләре булмаган, иң яхшы, иң уңган гүзәл зат бит инде, мин дә шулай уйлыйм.

Казан мәдәният институтында укыганда, бездә Нәҗибә апа Ихсанова «Театр сәнгате»н алып барды. Төркемебездә 4 егет, 10 кыз иде. Шулай, дүртенче курста укыган чак булды микән, бүлмәне җыештырырга керештек. Кызлар сәхнә идәнен юа, без су ташып, чүп түгеп йөрибез. Шунда Зинирага күзем төште. Башка кызлар җирәнеп, «уф»ылдан, пирчәткәләр киеп кенә юган була, ә Зинира идән чүпрәген әйбәтләп сыкты да бөтен җирне ялт итеп юып та алды. Иң беренче куллары на күзем төште. Белмим, нигә алайдыр, әмма мин хатын-кызларның кулларына игътибар итәм. Зиниранык ы шулкадәр матур, нәфис иде. Шундук гашыйк булдым, кыскасы.

Зинираны, иң беренче чиратта, балаларымның әнисе булганы өчен хөрмәт итәм. Аларны да, мине дә чиста, пөхтә итеп киендереп, гел тәртиптә тота ул. Минем күптәннән кибеткә барып, кием алганым юк. Барысы өчен Зинира җаваплы. Өйләнгәнче мин парфюмның нәрсә икәнен белми идем диярлек, хәзер һәр очрак өчен – аерым ислемай минем. Зинираны зирәк, вакытында әйтелгән киңәшләре өчен дә хөрмәт итәм. Ул кешеләрнең нинди булуын яхшы чамалый. Мин кайберәүләр турында: «Менә бу – бик яхшы кеше, аңа ышанырга була», – дисәм, игътибарлырак булырга куша. Аннан күпмедер вакыттан соң ул кешенең чын йөзе ачыла. Зинира – гади, үз кеше. Менә шуңа күрә дә яратам мин аны.

АЙДАР ГАБИДУЛЛИН: «УЛ МИННӘН ДӘ, ҮЗЕННӘН ДӘ РӘХӘТЛӘНЕП КӨЛӘ БЕЛӘ»

Т.Биктимирова архивыннан

Икенче рәттә Хәдичә Ямашева, Мәдинә Терегулова, Хөсәен Ямашев

XIX йөзнең соңгы яртысында аеруча үсеп киткән мәгърифәтчелек хәрәкәте татар кызларының язмышына уңай үзгәрешләр кертә. Шифалы яңгырдан соң үсеп чыккан гөлләр кебек, белем алырга, әдәбият мәйданында үз көчләрен сынап карарга теләүче йөзләрчә каһарман йөрәкле кызлар табыла. Игелекле татар байлары ярдәмендә кызлар өчен мәдрәсәләр, дин гыйлеме белән бергә дөньяви фәннәр дә укытылган мәктәпләр ачыла. Татар кызлары рус кызлары өчен генә ачылган төрле уку йортларына кереп белем алалар һәм хәтта Европа илләренә чыгудан да курыкмаучылар табыла.

«Чистай өязенең мәгърифәт йолдызлары». Әкияттәге кебек 12 кыз турында язылган китап әнә шулай атала. Ни өчен нәкъ менә Чистай төбәге? Китапның мөхәррире, автор-төзүчесе Тәэминә апа Биктимирова белән шул сорауга җавап эзлибез.

Закир ишан

Бу төбәктә мәгърифәтчелекнең алга китүе Чистайның Россия күләмендә мәшһүр ишаны, күренекле мәгърифәтче һәм II гильдия сәүдәгәре Мөхәммәтзакир Габделвәһаб улы Камаловка бәйле була. Ул үз акчасына Чистайда зур гына мәдрәсә салдыра һәм 46 ел буена шул мәдрәсәнең мөдәррисе булып хезмәт итә. Тырыш хезмәте өчен зур көмеш медаль белән бүләкләнсә дә, гомеренең соңгы елларында ачыктан-ачык татар халкы мәнфәгатьләре хакына көрәшкәне өчен хакимият тарафыннан эзәрлекләнүләргә дучар була. Бу мәдрәсәдә укып белем алган Риза Фәхретдин, Фатих Кәрими, Гаяз Исхакый исемнәрен атау гына да күп нәрсә турында сөйли. Ишан гаиләсендә сигез кыз һәм бер ул туа. Әтисенең иң якын ярдәмчесе булган Ибраһим башлангыч белемне әтисе мәдрәсәсендә ала. 1902–1903 елларда Шәрык дөньясының иң мәшһүр уку йортларыннан саналган Әл-Әзһәр (Каһирә) университетында укый. Сеңелләре Шәмсениса, Хәтимә, Гөлсемне Ибраһим өйдә үзе укыта. Алар янына киләчәктә татар мәгарифенең гүзәл энҗеләре булачак Фатыйма-Фәридә Ваһапова-Нәүрүзова, Мәрвәрит һәм Илһамия Туктарова һәм башкалар кушылып белем алалар, гимназиягә, югары уку йортларына керергә әзерләнәләр.

«Җан апа»

Чистайның мәгърифәтче хатын-кызлары турында сүз чыкса, һичшиксез, беренче булып Хәдичә Ямашеваны искә алалар. Рәхим-шәфкатьле, җылы күңелле булып, кылган яхшылыклары өчен якын туганнары Хәдичә апаларын «Җан апа» дип йөрткәннәр. Хәдичә Бадәмшина 1881 елда Чистай шәһәрендә туа. Заманында танылган сәүдәгәр булып, соңрак бөлгән һәм дин-шәригать юлында гына йөргән Зарифның бердәнбер кызы ул. Әтисенең энесе Гариф азатлык өчен көрәшкә тартылган кеше буларак, бу йортта революционерлар да еш кунак була. Шуңа да Хәдичәнең Хөсәен Ямашев белән танышып китүе, аңа кияүгә чыгуы гаҗәп хәл булмый.

1917 елны Мәскәүдә яшәүче татар хатын-кызлары Бөтенроссия мөселман хатын-кызлары корылтаен уздыру тәкъдимен күтәреп чыгалар. Комитетка мөселман хатын-кызлардан әгъзалар сайлаганда, Хәдичә Ямашева исеме иң беренчеләрдән әйтелә. Соңыннан корылтайның «Вакытлы мәркәз бюросы» оештырылып, аның рәисе итеп тә Хәдичә ханым сайлана. Корылтайга Россия, Кавказ, Кырым, Төркестан, Польша хатын-кызларыннан 71 делегат килә. 1937 елны кулга алынгач, шушы корылтайны оештыруы аңа төп гаепләү акты булачагын ул, әлбәттә инде, күз алдына да китерә алмагандыр. Корылтайдан соң «Мөслимәләр җәмгыяте» төзелә һәм аның рәисе вазыйфасы да Хәдичәгә зур ышаныч белән тапшырыла. Шул ук елны Казан шәһәре Думасына үткәрелгән сайлауда депутат булып та сайлана.

1923, 1932 елларда Хәдичә апаны ике тапкыр кулга алалар. Аңа тагылган гаеп бүген дә гаҗәп тоела. Янәсе, теш куйганда, дәүләт алтынын әрәм-шәрәм иткән булуы бар. Тарихчылар фаразлавынча, төп сәбәп туган иленнән бөтенләй аерылып китәргә мәҗбүр булган энесе Фуад Туктаров булуы мөмкин. Чөнки 1937 елда өченче тапкыр кулга алынгач, нәкъ менә шул ак эмигрант энесе белән бәйләнеше дә советка каршы җинаять эше дип бәяләнә. Болларга өстәп, Хәдичә Ямашева-Таначеваны (Хөсәен Ямашев 1912 елда вафат була, ул Вәлидхан Таначевка икенче тапкыр кияүгә чыга) советка каршы шпионлык эшендә гаеплиләр. Ире белән кулга алынып (бу вакытта аларның икесенә дә 56 яшь була), Коми АССРның Ухтижим лагерендә 8 ел буе интегәләр. Мәгълүматлардан күренгәнчә, Хәдичә лагерьда да байтак тоткыннарга ярдәм кулы суза.

1945 елның ноябрендә аларны азат итәләр, әмма илдәге кулга алынуларның икенче дулкыны башлангач, 1949 елны бу бәхетсез җаннарны яңадан кулга алалар (аларга инде 66 яшь тулган була). Сеңелләре Илһамиянең дә язмышы шундый ук була. Бу юлы аларның өчесен дә Красноярск краена сөрәләр. Хәдичә шуннан туган иленә кайта алмаган. 1952 елда вафат булган. Красноярск краеның Абан районы Эстәрлетамак авылы зиратында күмелгән. Вәлидхан Таначев, үзе азат ителү белән, сөеклесенең каберенә чардуган куеп, таш ясата алган. Хәдичә апа турында килеп ирешкән соңгы хәбәрләр турында Тәэминә ханым менә ниләр сөйләде:

– 2014 елны Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты каршындагы «Ак калфак» хатын-кызлар оешмасы икенче форумын үткәрде. Утырышта кыскача гына XX йөз башында яшәгән хатын-кызларыбыз хакында сөйләдем. Красноярск краеннан килгән бер ханым мине эзләп тапты да: «Апа, сез сөйләгән Хәдичә апа безнең авылда яшәгән бит, минем бабам аның каберен карап, чистартып яшәде, фоторәсеме безнең авыл музеенда саклана», – диде. Мин куанычымнан елый-елый аңа рәхмәтләр әйттем. Форумга килгән Нурия Фәйзуллина белән Нурилә Кәримова иде алар. Озакламый алардан хат алдым. Анда мондый сүзләр бар иде: «Өлкәннәр сөргендә булучыларны хәтерлиләр. Аларга рөхсәтсез авылдан чыгып йөрү тыелган була. Вәлидхан абзый колхозда счетовод булып эшләгән. Ә хатын-кызлар йортта кул эшләре белән шөгыльләнгәннәр. Хәдичә ханым Себердә бер ел ярым чамасы гына яшәп, 68 нче яшендә вафат булган. Моталлап бабай кабергә карагай агачыннан чардуган ясаган, ә аның Хәсән исемле улы тимерләр белән ныгыткан. Мәрмәр плитәдән эшләнгән кабер ташы озак еллар торды әле. Хәзер дә ул ташта татарча язылган кайбер сүзләрне укырга була. 2016 елның 14 сентябрендә Татарстанның күренекле кызы Хәдичә Ямашева-Таначеваның кабергә яңа чардуган һәм яңа кабер ташы куелды…» Гаҗәп бит: әйтерсең лә Хәдичә апа «Мине онытмагыз!» дип хәбәр җибәреп тора.

«Милләт анасы»

Якты дөньяда нибары 25 ел гына яшәсә дә, замандашларына иң матур истәлекләр калдырган Фатыйма-Фәридә Ваһапова-Нәүрүзова аерым урынны алып тора. Ул – педагог, журналист, публицист, хатын-кызлар хокукы өчен актив көрәшче. Мөселман хатын-кызларыннан иң беренче публицист-мөхәррир Себердә «Сибирия» исемле беренче татар газетасын чыгара. Яшь кенә булса да, Бөтенроссия мөселман хатын-кызлары корылтаенда аны хөрмәтләп, «милләт анасы» дип атыйлар.

Фатыйма-Фәридә башлангыч белемне абыстайга йөреп ала, әмма бу аны канәгатьләндерми. Әтисе Мортаза Ваһаповның да бердәнбер кызына дөньяви белем бирәсе килә. Тик яман сүзләр чыгудан курка. Ниһаять, җае чыга: әйткәнебезчә, Закир ишан кызларына кушыла.

1907 елны Мортазалар гаиләсе хәзерге Ютазы районының Кәрәкәшле авылына күчеп килә. Зур кыенлыклар белән Фатыйма анда кызлар өчен җәдит мәктәбе ача. Ләкин бу эш шома гына бармый. Ничә еллар буена дин дәресләре өйрәткән Бәдрикамал абыстай кызларның, дөньяви дәресләр алып, «шайтан юлы»на басуларына ризалык бирми. Ә авыл халкы аның бәддогасыннан курка. Хәдичәнең әнисе, шәлен ябынып, авыл буенча кызларның әти-әниләрен үгетләп йөри. Атна кичләрен Фатыйма мәктәбендә авыл хатын-кызлары да җыелып дәрес ала. Әкренләп күрше авыллардан да киләләр.

1908 елны Фатыйма Төркиядә укып кайткан, чыгышы белән шушы Кәрәкәшленеке булган Вагыйз Нәүрүзовка кияүгә чыга. Алар Томск шәһәренә күчеп китәләр. Ерак җирләргә күчеп китүнең сәбәбен ул болай аңлата: «Без зәгыйфь вә аянычлы милләтебезгә хезмәт итүне беренче бурычымыз дип белдек. Шул сәбәпле бу хезмәтне җан-тән илә кабул итеп, бер кашыклы канымыз калганчы милләткә хезмәт итәчәкмез». Үз ватаныгызда да хезмәт итәргә мөмкиндер бит, дигән сорауга ул: «Алай да мөмкин, тик анда бездән башка да хезмәт итүчеләр бар, шөкер», – дип җавап бирә.

Томскида Фатыйма татар кызлары өчен мәктәп ачарга уйлый. Шуңа күрә укытучылыкка имтихан тапшыра. Һәм бу адымы аңа мәктәпне казна хисабына ачарга мөмкинлек бирә. 1912 елны алар «Сибирия» газетасы чыгара башлыйлар. Газетаның чыгымнары өчен Мортаза карт Чистайдагы тегермәнен сата. Фатыйма анда «Хатын-кызлар дөньясы» дигән бүлек тә оештыра. Газетаның бөтен эшен үзе алып бара. Кыскасы, ничаклы эшләргә мөмкин булса, шул чаклы эшли.

Ни кызганыч, Фатыйма шәхси тормышында бәхетле була алмый. 1913 елның ахырларында ул, каты авыру хәлендә, улын ияртеп, Кәрәкәшлегә әтисе йортына кайта. Бердәнбер кызларын югалту алдында кара кайгыга баткан Мортаза абзый белән Фатыйма абыстай кызларының васыятен сорыйлар. «Булган нәрсәләремне сатып, шушы Кәрәкәшле авылы балаларына минем исемемнән мәктәп салсагыз иде», – ди ул. Бу – Фатыйманың соңгы васыяте.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ОСТА КЫЗЛАР

Апас районының Борнаш авылында гомер итүче Җәләлиевләрнең дүрт кызлары да атлар ярата. Шуңа гаилә күпләп мал тота. Кызлар атларга кечкенәдән ияләнгән. Исламия белән Илүсә Сабан туенда ат чабышында катнашып, җиңү дә яулый.

– Кызлар булсалар да, малайлар кебек кыю булып үстеләр. Без теләкләренә каршы килмәдек. Кызларым атларның кәефен дә сизә, нәрсә ашатырга яраганын да белеп торалар. Безнең атлар печән, арпа, солы гына түгел, кишерне дә бик ярата. Ә менә атларга алма бөтенләй бирергә кирәкми, – дип сөйли Гөлүсә ханым.

– Кызларым ат өстендә килеш йоклап та китәләр иде. Эзләп чыксам, шаккатам. Аты да тыныч тора бит аның. Исламия кызым теләсә нинди холыклы атны да тыңлата ала.

Гөлүсә ханымның да тик торганы юк. Ул бик оста итеп киемнәр бәйли. Шкафы җепләр белән тулган аның. Бер эшли башласа, туктатам димә. Тотынса, җиренә җиткерә торган кеше.

– 6 нчы сыйныфта укыганда кулыма җеп килеп керде. Бәйлисем килә генә бит. Ул чакта мәктәптә укытучыбыз Мәдинә Абзалова бәйләү түгәрәгенә алып бара иде. Безне ул өйрәтте. Хәзер инде бәйләү үрнәкләрен табу кыен түгел. Апам Чулпан да бик оста бәйли. Киңәш кирәктә аңа шалтыратам, – ди ул.

Гөлүсә ханым ире Илсурга да, кызларына да бөтен киемне үзе бәйләп кидергән. Кызларга бәйләгән күлмәк-кофта, свитерларның исәбе юк икән. Ә менә иренә 17 кофта бәйләгәнен санап барган. Хыялы да бар – килчәктә сарафан, пәлтә, экотун бәйләргә җыена.

– Үзең бәйләгән сыйфатлы була инде. Башка кешедә булмый. Шуңа да кызларыма гел бәйлим. Җепкә акча кызганмыйм. Сыйфатлысын алам. Арзанга кызыксаң, киемнең төсе дә башка була. Әле соңгы вакытта ыргак белән дә бәйли башладым. Башлык, шарфларны шуның белән бәйлим, – ди Гөлүсә ханым. – Бәйләү өчен үрнәкләрне интернеттан алам. Гел андагыча да итмим. Кайберсен үзгәртеп куям. Әгәр мин теләгәнчә килеп чыкмаса, сүтәм дә атам.

Сөйләшә торгач, уңган ханымның тагын бер һөнәре барын белдек. Ул сәйлән һәм энҗе-мәрҗәннәрдән агачлар, гөлләр дә үрә икән.

– Элек балалар бакчасында эшләгәндә, сабыйларга гөлләр төрен аңлатыйм дип бу эшкә тотынган идем. Үземә ошап китте. Вак эш булса да, яратып ясыйм. Иренмәскә кирәк. Теләк булса, бар да була, – ди ул. – Эштән ямь табарга өйрәнгән инде мин. Нәрсә эшләсәм дә, күңел җылымны кушам. Шуңа да минем кул эшләрен яратып кияләр, кадерләп саклыйлар. Миңа исә күп кирәкми, кешегә ошаса, шул җитә.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

«ИРКӘ ХАТЫН ДА БУЛАСЫ КИЛӘ»

Балык Бистәсе районының Чыршылы Елга авылында яшәүче Лена Осина, ирем юк, дип тормаган, ике катлы йорт торгызган. Акчаны исә аңа сигез ел җыярга туры килгән. Җиләкче, гөмбәче, балык ыслаучы, таксист – ни белән генә шөгыльләнми ул! Белмәгән эше юк: бәйләвен дә бәйли, тегүен дә тегә, йонын да эрли.

Өй төзү хыялы булган аның. Хәзер яши торган йортлары иске икән. Бер төзүчедән, өй салыр өчен нинди материал сатып алырга икән, дип кызыксынгач: «Син бернәрсә дә алма, бары акчаңны гына җый», – дип киңәш иткән. Шулай иткән дә: тиенләп җыелган акча өйне түбә астына кертергә җиткән. Әкренләп идән җәйгәннәр, диварын акшарлаганнар. Ут кертер өчен генә дә 100 мең сум киткән. Газын да кертсәләр, яңа йортка күченеп булачак.

Алма, пеш, авызыма төш, дип ята торганнардан түгел Лена. Тик ятсаң, берни булмый, бу – тормыш кагыйдәсе. Нинди эш акча китерә, шуңа ябышкан. Берьюлы берничә эшне үтәгән: таксист, иминият агенты, балык ыслаучы, гөмбә тозлаучы… Көнгә 200 кило балык чистартып ыслаган хәтта. Элек мал-туарын, сыерын да асраганнар. Хәзер кәҗә белән тавыклар гына тоталар. Сөт, йомырка җитә, итен сатып алалар. Хәзергә вакытта кафеда эшләгәч, башка нәрсәгә артык вакыты калмый икән. Кирәк кешегә көзен гөмбәсен тозлап, җәен җиләген җыеп сата.

– Каен җиләге, гөмбәне 5–6 яшьтән үк җыям. Йокլап яту дигән нәрсәне белмәдем. Иртәнге сәгать алтыда торып, урманга китә идек. Кулга банка түгел, чиләк тоттыралар иде. Әни гөмбәне белеп җыярга өйрәтте. Улым Русланга хәзер 17 яшь. Тик мин аның үзен генә җиләккә җибәрмим. Вак эшләр кушмыйм, чөнки авыр икәнен беләм, – ди Лена. – Башта үзебезгә җыйдык, аннан башкалар сорый башлады. Яхшы товарны беркайчан да күрсәтеп йөрергә кирәкми. Заказны күрше авыллардан да бирәләр. Гөмбәнең иң яхшыларын җыям. Ак, җирән гөмбә, гөреҗдә, баллы гөмбә… Биш тапкыр пешереп, суын түгә торганнарны башкаларга тәкъдим итеп тә тормыйм. Үзем 100 процент канәгать калганда гына башкаларга сатам. Ашарга пешерергә кечкенәдән өйрәндем.

Махсус китап бар иде, хәзер саргаеп бетте инде ул.

Лена өчен күңел тынычлыгы – беренче урында. Исерек ир белән җәфа чиккәнче, ялгыз яшәвең мең артык, ди. Дөрес, иркә хатын буласы килгән чаклары да булгалый. Көчле хатыннарга көчсез ирләр туры килә, дип тә куйды ул. Язмышы белән килешә, моңа һич тә үпкәләми. Күптән түгел исемен дә алыштырган әле. Хәзер ул – Лилия! Яртылаш – татар, яртылаш рус кызы ул. Әлеге исем тормышыңны яңа якка үзгәртсен, иркәләнергә дә язсын сиңа, көчле зат!

Сәрия МИФТАХОВА

Уенчыкта – кул җылысы

Ул ясаган уенчыклар арасында нинди генә мультфильм геройлары юк. Чүпрәле районының Шланга авылы кызы 25 яшьлек Райлә Сатдинова баштарак аларны якын дусларына, туганнарына бүләк итсә, хәзер инде уенчыкларын сатып алырга теләүчеләр дә күп икән. Райләнең башка һөнәрләре дә бар. Ул бик актив яши. Ә бит кыз тумыштан йөри алмый…

– Мәктәпне алтын медальгә тәмамладым. Тукталып каласым килмәде, югары уку йортына кердем. Шул вакытта академик ишү белән шөгыльләнә башладым. Ул миңа бик ошый. Төрле ярышларда катнашам. Россия чемпионатында җиңү дә яуладым әле. Гомумән, мин спорт белән яшим. Коляскада утырып волейбол уйныйм. Татарстан җыелма командасында чыгыш ясыйм, – ди ул.

Райлә Казаннан фатир алган. Иң зур хыялы шул була аның. Шөкер, хәзер үз куышы бар. Әнә шул куышында – әкият дөньясы. Буш вакыты булдымы, кул эшенә тотына. Уенчыкларны бик яратып ясый.

– Интернетта йомшак уенчыклар күреп алгач, үземнең дә ясыйсым килеп китте. Кирәкле чималларын сатып алдым да ясарга булдым. Беренчесе үк бик матур килеп чыкты. Аны шундук сатып алдылар. Әкренләп, курчаклар да ясый башладым. Аларын бигрәк яраталар, – ди Райлә.

Бер уенчыкны ясар өчен ике көн китә икән. Катлаулырак булса, берничә көнгә дә сузыла.

– Мин бу шөгылемнән ямь табам. Күңелем тынычланып, бар борчуларым юкка чыга. Кулыма уенчык алмаган көнне бушка узган дип саныйм. Хәтта авылга кайтып килгәндә дә, эшемне сагынам. Йокламасам йокламыйм, уенчыклар ясарга тотынам, – ди ул.

Курчакларны ясау җиңел түгел. Әмма кыз бирешми, аларны оста итеп ясап куя. Башта курчагын, аннары киемнәрен әзерли. Анысына да ихтыяж зур, ди.

– Уенчыкларны, интернеттан күреп, кемнәр генә сорамый. Россиянең төрле шәһәрләренә таралды эшләрем. Һәркем үзенә нинди уенчык тели, шуның рәсемен җибәрә. Кайчак ничек эшлисен интернеттан карыйм, кайберләрен үзем белеп эшлим, – ди Райлә. – Бүләккә дип алган уенчыкларны үзләрендә калдыручылар күп икән. Кешеләр яраткач рәхәт инде. Соңгы арада заказларым аеруча күп. Әллә ни зур акча килмәсә дә, иш янына куш. Миңа бик тә ярдәм итә.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КҮГӘРЧЕН ОЯСЫМЫ, ОЧА ТОРГАН УКЛАРМЫ?

КАМАЛ ТЕАТРЫНЫҢ ЯҢА БИНАСЫ УҢАЕННАН ТӨП СОРАУЛАРГА АЧЫКЛЫК КЕРТӘБЕЗ

wowhaus.ru

Камал театры күченәчәк, дигән хәбәр җәмәгатьчелекне бер селкетсә, җиңүче проект буенча да сораулар һәм тәкъдимнәрнең тынганы юк әле. «Мәскәүнең Wowhaus бюросы әзерләгән проекта миллилек бармы?», «Нишләп парковка турында сүз юк, әллә ул каралмаганмы?» – дигән сорауларга залның 600 урынлы гына булуына ризасызлык та өстәлде. Хуҗалыкны кайгыртучан халык буларак, бу бинаның чыгымлы булуын фаразлаучылар да булды. Бу сорауларга карата белгечләр фикерен белештек, Камал театры җитәкчелегеннән ачылык кертүен сорадык.

Финалда җиңгән Wowhaus бюросы Япониянең Kengo Kuma & Associate, Германиядән Werner Sobek AG компанияләре һәм Казаннан Герман Бакулинның шәхси иҗаты остаханәсе берләшмәсе ул. Алар проект яклаганда татар халкының гореф-гадәтен бик җентекләп өйрәнүләре, безнең архитектурада ук элементының булуы турында сөйләгәннәр иде.

Безнең архитектура дигәндә, нәрсә күз алдына тотыла? Гомумән, милли архитектура бармы бездә? Фольклор белгече Фәнзилә Җәүһәрова «юк» дигән фикердә:

– Проект турында без әлегә фотосурәтләрдән чыгып кына фаразлый алабыз. Аңлавымча, анда кызыл төс өстенлек итә. Зал бизәлешендәге татар сөлгесе дә шуңа ишарә. Бу – Казан арты сөлгесе һәм аның асылында фин-угор традицияләре ята. Милли сәнгатьтә ак һәм кызыл төсләргә урын бирелсә дә, алар төп урынны биләми. Ул – агрессив төс. Милли бизәкләр нигезендә исә үсемлек орнаментлары ята. Әлбәттә, яңа формаларны эзләргә кирәк, әмма 100 елдан артык тарихы булган театрда калыплашкан образлар да булырга тиеш дип саныйм.

> Нинди генә кәттә архитектор да, янында татар символлары белән эшләүче булмаган очракта, миллилекне саклый алмый. Чөнки ул образларны белми.

Хәзерге бинаны алыйк. Тышкы яктан караганда, анда миллилек бөтенләй юк, ул Кабан күле буенда туктаган корабны хәтерләтә. Ә инде бизәлешләре алсак, анда театраль битлекләрне татар милли орнаменты стилендә эшләгәннәр. Бу бинаны да ошатучылар бик аз, тик ул һич югы безнең климат шартларына җайлаштырып эшләнгән. Мәсәлән, анда түбә чистарту кайгысы юк. Яңа бина түбәсен күз алдына китерик. Кемдер аны күгәрчен оясына, ә мин яткырылган шпильләргә охшаттым. Җиңелгән гаскәрнең яткырылган байрагы. Уклар икән, ул күккә ашар иде. Кызганыч, Казанда татар архитектурасы дип күрсәтерлек үрнәк тә юк. Сәйдәш исемен йөрткән зур концерт залын гына алыйк. Ул шулкадәр җансыз, котсыз. Яшел һәм коңгырт плитәләрдән төзелгән орнаментларның, кызганыч, нәфислеге юк. Цирк бинасы совет вакытына ярашлы булгандыр, ремонт вакытында аңа аз гына булса да кот кертеп була иде бит. «Пирамида»ның безнең архитектурага ни катнашы бар? Җир асты патшалыгы җанварлары образлары чорнап алган «Чаша» безгә төсме? Әгәр инде милли архитектура булдыру максаты куела икән, кичекмәстән милли белгечләр әзерләргә кирәк. Азәрбайҗанда концерт залы бар, ул хатын-кыз яулыгы (башлыгы) формасында эшләнгән. Ник дигәндә, төркиләрдә хатын-кыз роле бик зур. Ир ат арасындагы конфликтны чишәр өчен ана уртага чыгып яулыгын ата торган булган. Бу низагны туктаткан. Концерт залы менә шушы символны хәтерләтә.

Проект сайлауда катнашкан зыялылар нинди фикердә? Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиевтән әнә шуны белештек:

– Әйтергә кирәк, Татарстанда моңа кадәр халыкара дәрәҗәдә иң зур белгечләр катнашында андый объект төзелгәне юк иде. Дөньяның атаклы архитекторлары Казанда объект төзүдә катнашалар икән, бу бик яхшы. Мин моны ни өчен әйтәм, чөнки Казахстанга баргач, Астана шәһәренең кыяфәтенә, андагы биналарга, архитектура үзенчәлегенә шаккаткан идем. Алар заманча, шул ук вакытта миллилек тә көчле. Ничек болай төзи алдыгыз, дип сорагач, бу биналарның проектларын безнең архитекторлар белән бергәләп, япон белгечләре эшләде, дип җавап бирделәр. Японнар заманча образын ясап бирсә, үзләренекеләр миллилек өстәгәннәр. Бездә дә шулай булыр дип уйлаган идем. Ни кызганыч, конкурста японнар да катнашты, алманнар да, башкалар да, әмма чын милли архитекторлар ни сәбәпледер катнашмады. Җиңеп чыккан проект командасындагы Татарстан вәкилен милли архитектор дип әйтергә телем әйләнми. Мин архитектор түгел, әмма ике таләбемне баштан ук әйттем: беренчедән, бинаның театр икәне әллә кайдан кычкырып торсын, икенчедән, аның милли төсмерләре булсын. Утырышта минем чыгышка каршы килүчеләр булды, аларга берничә ел элек Япониянең Токио шәһәрендә күргәнемне сөйләдем. Бер бина каршында тукталгач, экскурсовод бездән, бу нинди корылма дип уйлыйсыз, дип сорады. Театр, музей дигән җаваплар булды. Баксаң, чүп яндыра торган завод икән. Хәзер яңа бинаны күз алдына китерик. Япониядән туристлар килде һәм без алардан, бу нинди бина, дип сорадык, ди. Алар театр дип җавап бирә алмас. Чүп яндыру заводы дип тә әйтергә мөмкиннәр әле. Ул Япониядәге әнә шул заводтан әллә ни аерылып тормый. Дөресен әйткәндә, ярымфиналга чыккан 8 проектның берсе дә минем таләпләргә җавап бирми иде. Аларның берсе дә сәнгать сарае дип кычкырып тормый, икенчедән, берсендә дә миллилек юк. Иң соңыннан җиңеп чыкканы бу җәһәттән азмы-күпме канәгатьләндерә әле. Эчендә азрак миллилек бар, тышында исә мин алга омтылыш күрәм.

> Бүген халыкның кәефе әллә ни яхшы түгел, бу җәһәттән ул алга омтылыш, динамика бирә. Шунысы да бар: без архитекторларга, бу проектлар әле камилләштерелергә тиеш, дигән таләп куйдык. Мондагы белгечләр, милли архитекторлар белән киңәшләшеп, театр әһелләренең фикерләре исәпкә алыныр дип уйлыйм. Әле бу – проектның нигезе генә.

Камал театры директоры Илфир Якупов залның ни өчен 600 урынлы булуы, парковка мәсьәләсе һәм укучылардан килгән башка сорауларга ачыклык кертте.

▶ **Ни өчен зур зал нибары 600 урынлы?** Зур залның 600 урынлы булуы, күрәсең, күп кешене аптырашта калдыргандыр. Театрның мондый адымга баруын тәфсилләбрәк аңлатып китик әле.

Бүген Камал театрының зур залы – 843, кече залы 162 урынлы. Яңа бинада зур зал 600 урынлы, моннан тыш 200 урынлы black box, 150–200 урынлы түгәрәк зал һәм 150 урынлы камера залы булачак. Барысын бергә исәпләгәндә, театр 1000нән артык тамашачыны кабул итә ала. Артистлар төрле залларга бүленеп уйнаячак. Эш тәртибе хәзер дә шулай. Мәсәлән, Чаллыда гастрольдә өч бинада параллель рәвештә спектакльләр күрсәттек.

Икенчедән, без бу карарга бик күп театрларның эшчәнлеген өйрәнгәннән соң килдек. Драма театрларында электроакустикадан тыш, тере тавыш белән эшләү гадәткә кергән. Һәм ул дөрес, шулай булырга тиеш. Тере тавыш булганда, бөтен тамашачы да артистны яхшы ишетмәскә мөмкин. Хәзерге залда арттагы рәтләрдә утыручылар, кызганыч, сәхнәдәге тамашаны ишетеп бетерми. Артистлар шуңа тавышын күтәреп уйнарга мәҗбүр. Алдагы рәттәге тамашачы исә еш кына, Камал артистлары бик кычкырып уйный, дип кисәтү ясый. Артист тикмәгә генә көчәнеп уйнамый инде ул. Аңа сүзенең балконның 8 нче рәтендә утырган тамашачыга да барып җитүе мөһим. Ә инде 600 урынлы залда эшләгәндә, артистның энергиясен тавышка түгел, роленә салу мөмкинлеге арта. Урын санын шуннан чыгып сайладык.

▶ **Проектта парковка каралганмы?** Әлбәттә, каралган. Аның җир асты өлеше дә булачак, бина янында «кесә»ләр дә каралачак. Әлегә план буенча хезмәткәрләр өчен аерым, тамашачы өчен аерым машина кую урыннары булачак. Әлегә күпме машина сыйдырышлы булачагын әйтеп булмый.

▶ **Бизәлеш мәсьәләсе.** Минемчә җиңгән проект башкаларына караганда күпкәятышлырак. Күпләр сәхнә кырые бизәлешендәге кызыл сөлгеләрне ошатмаган. Аларга җентекләп карарга киңәш итмәс идем. Ул спектакльгә карап үзгәрәчәк. Диварларда махсус җайланмалар урнаштырылачак һәм аларга декорация буларак хезмәт итәчәк.

▶ **Бинаны карап тоту чыгымлымы?** Проект төзелгәндә һәм төзелеш вакытында иң оптималь вариант сайлап алыначак. Бинаны карап тоту җайлы булсын өчен барысы да эшләнер дип уйлыйм. Хәзерге вакытта Казанда түбәсе җылытыла торган берничә бина бар. Бәлки ул үрнәк кулланылыр. Эксплуатация кыйммәткә чыкмасын өчен иң кулай вариант сайлап алыныр дип уйлыйм.

Яңа театр сәнгать зонасында урын алачак. Билгеле, бу – тарихи яктан татар элитасы кайнаган урын түгел. Камаллылар еш кына, театр кайда – тамашачы шунда, дип әйтергә ярата. Яңа бина үзәкне тагын да киңәйтә икән, афәрин генә. Тарихи үзәктән куылу дип кенә кабул итәлмәсен. Һәм соңгысы. Зурдан кубып башланган эш тукталып калмасын, барлык фикерләрне исәпкә алып, камилләшеп, сафка бассын гына иде инде.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

< Дәвамы. Башы 25 февраль санында

ФИРДҮС ГЫЙМАЛТДИНОВ

СОВЕТ МУЛЛАСЫ

ХИКӘЯ

Дин ягыннан аларның авылы халкы шактый үзенчәлекле. Сүз дә юк, заманында, куркытылып, өркетелеп, көчләп чукындырылган кешеләре дә булган. Ләкин алар да, афәт бераз чигенә төшкәч, кире үз кыйблаларына кайтканнар. Беркем дә моның өчен үзләрен кимсетмәгән дә, каты сүз дә әйтмәгән. Заманасы шундый булган, нишлисең?! Хәер, ул хан заманындагы вакыйгаларны Гарәпша да олыларның телдән-телгә сөйләвеннән генә белә, үзе күргән гарасатлар түгел.

Башларын орып биш вакыт намаз укымасалар да, авылдашлары, шул исәптән Гарәпша да беркайчан да иманны, динне ташламады. Мәчет манарасын 1939 елда кисеп, мулланы куып җибәргәч тә озак үтмәде, сугыш бетүгә ике еллар чамасы узгач, авылга мулла итеп Гыйльмулла абзыйны сайлап куйдылар. Ничектер үзеннән-үзе килеп чыкты ул хәл. Зират өстендә чираттагы мәетне җир куенына озаткач, таралышырга өлгермәгән ир-атларга берсе көтелмәгән тәкъдим ташлады:

– Егетләр, болай имансыз-денсез яшәп булмый бит инде. Мәет җирләгәндә дә алмаш-тилмәш укыйбыз, һәркем үз белгәнен. Авылга мулла кирәк, ансыз тормыш бармый. Менә хәзер мәрхүмнең өчесен, җидесен укытасы. Балалар туып тора. Аларга исем куштыру үзе бер мәрәкә. Никахын әйткән дә юк. Кеше-карага тавыш-тын чыгармый гына мулла сайлап куйыйк, әйдәгез! Зират өстенә тәртип салып торуда ул башлап йөрүче булыр иде...

Ир-атлар тынып калды. Кемнең дә ни дип тә әйтергә теле әйләнмәде. Шуннан икенче бер агай тавышы ишетелде:

– Гыйльмулла абзыйны куярга кирәк! Тәртибе дә менә дигән, арабызда иң өлкәне дә ул...

– Соң, егетләр, мин ничек муллалыкка керешим ди?! Дин хәзер, үзегез беләсез, кычкырып йөри торган нәрсә түгел... – дип тәмам аптырашта калды Гыйльмулла карт. Дулкынлануыннан маңгаена тир бөрчекләре үк бәреп чыкты.

– Кычкырырга кирәкми, эчтән генә укырсың, Гыйльмулла абзый! Син – пенсионер, сиңа беркем бер сүз дә әйтә алмый, кимсеттермәбез дә. Кирәк икән, авыл белән якларбыз үзеңне!

Шулай да, урамдагы берничә ир-атны чакыртып, Гарәпша ул сөякләрне казып алырга кушты, саклык белән кәфенлеккә төрде, шул ук зиратның уртарак бер төшенә яңа каберлек казытып, догаларын укып, барлык шартын китереп күмдерде. Изгеләр зираты дип атыйлар аны авылда. Һәрбер яткан бәндәсе изге булмагандыр анысы. Ләкин халык күңеленә шулай кергән икән, бәхәсләшү урынсыз. Үзе дә, бик авыр чакларында, шушында чыгып намаз укыганнарын, Аллаһыдан ярдәм сораганнарын хәтерли Гарәпша...

...Егерме елдан артык вакыт узган икән шул инде. Тыныч кына пенсиясен алып, карчыгы Шәмсекамәр белән рәхәтләнеп яшәп яткан чорлары. Балалары үсеп, кайсы кая таралышты, икәү кечкенә генә йортта торып калдылар. Артык нәрсә кирәкми үзләренә, берничә сарык, кәҗә, кош-корт асрап, Ходайның биргәненә шөкер итеп көн күрделәр.

Ул вакытта әле шактый сүз булды, ләкин Гыйльмулла абзыйны, зират өстендә бәхәс куерту килешми дип, тиз арада күндереп тә куйдылар.

Совет властена да бирешми оешкан мәхәллә әнә шулай матур гына эшләп тә китте. Һәрберсе мулланың сүзен карусыз үти, төрле мәҗлесләрдә түргә утырта, үзе белгәнчә әмәлләгән вәгазьләрен дикъкать белән тыңлый. Гаетләрне зират өстендә укырга карар кылдылар. Парторглары бераз мырлап караган иде дә, аны да тәмуг уты белән өркетеп, авызын яптырдылар. Ни гаҗәп, районнан килеп, җәмәгать хөкемнәре оештырып, дин таратуда гаепләп йөрүчеләр табылмады. Менә шулай авыл, сугыш бетеп бераз гына вакыт үтүгә, яңадан муллалы төбәккә әйләнде...

Киребеткән, үзсүзләрәк халык яши авылларында. Тик дин ягыннан, әллә ни белемле булмасалар да, Аллаһыдан ярдәм сорап, гөнаһлары өчен куркып торырга өйрәтелгәннәр. Яшьли тәрбия шундый. Тәне буе каядыр салгалап йөрсәләр дә, гаеткә берсе дә килми калмый, зират өстендә тәмәке көйрәтми, начар сүз сөйләми. Язларын зират өстен чистартуга да барысы да оешып катнаша. Дөрес, араларында, өмә тәмам булгач:

– Мондый изге эштән соң бер иллене тотып кую һич гөнаһ түгелдер, шәт, – дип әйтүчеләр дә бар. Шаяртып та әйтмиләр тагын, сүзләре ихлас. Тик анысына гына түзәргә була. Үзеңнән кала, башкаларны әүлия дип уйлыйсың да ары китәсең.

Кеше гомеренең үз чиге бар. Революцияләрне, ачлык елларын, аннан соң сугыш хәсрәтен күргән агайлар да, бирешмәгән төсле кылансалар да, картая бардылар. Гыйльмулла абзый да бер мәлне урамда күренмәс булды. Гарәпша, аның янына кереп, хәлләрен белешеп чыкты – тегесе, тәмам бетешеп, урын өстенә калган иде.

– Гайникамал, әнә тегендә, комод тартмасында минем китапларым бар, шуларны чыгар әле, – дип ымлады Гыйльмулла абзый, Гарәпша аның хәлләрен белешкәч, авылдагы яңалыкларны дикъкать белән тыңлагач та.

Гайникамал карчык, кабалана-кабалана, кырыс иренең кушканын үтәргә ашыкты. Комод тартмасыннан дөнья хозурына битләре тетелеп, саргаеп беткән ике китап чыкты. Саклык белән шуларны бисмалласын әйтеп кулга алгач та, Гыйльмулла абзый аларга тирән уйга батып берара уйланып карап торды. Аннан соң Гарәпшага сузды.

– Мә, Аллага тапшырып, синеке булсыннар.

Гарәпша аптырап калды:

– Нигә миңа?!

– Башың эшли, күңелең якты, иманың нык. Гарәп имлясын яхшы беләсең. Сиңа боларның тиздән кирәге чыгар. Соңгы васыятем, аңа каршы килергә хакың юк, Гарәпша энекәш.

Гарәпша калтыранган куллары белән теге китапларны алды. Гайникамал карчык шунда ук зур гына бер гәҗит табып китерде, китапларны аптырап утырган Гарәпшадан үзенә бирүен сорады, аннан соң, бик җайлап кына кәгазьгә төреп, кире сузды.

Әллә нинди бер гаҗәеп рәвештә сакланып калган дини китаплар иде бу. Берсе – борынгы Коръән. Икенчесе исә – дини йолалар тасвирланган басма. Тышлыклары юкка чыккан, кайбер битләре дә җитенкерәми. Шулай да аларга бик кадерле мәгълүмат тупланган. Кайткач та, Гарәпша, сыңар күзенең бар егәрен җыеп, шул гасырлар аша килеп җиткән әсбапларны өйрәнергә кереште.

Гыйльмулла абзый урын өстендә озак ятмады – җәйнең кыска төннәренең берендә, таң алдыннан бакыйлыкка күчте. Аны бөтен халык белән зурлап озаттылар, күрше авыллардан килүчеләр дә байтак иде. Хатын-кызлар, зират өстенә керми, мулланы җирләүне урам ягыннан гына күзәтеп тордылар.

Шуннан соң җәмәгатьтә янә сорау туды – кемне мәхәллә башлыгы итеп куярга?!

– Гарәпша абыйны муллалыкка билгеләргә кирәк! – дигән сүзләрдән Гарәпша сискәнеп китте. Һич көтелмәгән тәкъдим иде бу. Ул, гаҗәпләнеп, тавышы килгән якка борылды. Садыйк карт икән. Хәер, тавышын таныды үзе, чыннан да ул микән дип инанасы гына килүе булды.

– Садыйк абзый, тукта әле. Авылның мулласы итеп иң олы кеше билгеләнә бит. Тәртибе шулай, – дип, ниһаять, аваз салырга җөрьәт итте Гарәпша. – Безнең арабызда иң өлкәне син түгелме соң?..

– Мин шул. Ләкин син әйткән тәртип ул беркайда да язылмаган да, дөрес тә түгел. Мулла икән, ул йөгереп йөрергә, барысына да җитешергә тиеш. Ә миннән нәрсә?! Комым коела, ике көннең берендә чирләп ятам. Аннан соң, мин Гыйльмулла абый авырган чагында, аның белән кереп сөйләштем, бу мәсьәләне дә килештердем. Икәү уйлашып, муллалыкка синнән дә әйбәтрәк кешене тапмадык. Җәмәгать, каршы чыгучылар юктыр бит?

Садыйк карт тирәсенә җыелышкан ир-атларны күздән кичереп чыкты.

– Юк, бик дөрес тәкъдим бу!

– Булдыра, Гарәпша абыйга бик килешә торган хезмәт!

– Гарәпша абый, карышып торма инде! – диештеләр тегеләре. Гарәпша кинәт үз өстенә авыр йөк ишелеп төшкәнлеген чамалады, нигәдер кеше арасында үзен ятим бәндәдәй хис итте. Ул, алар белән бергә басып торса да, аерым шикелле. Авыл халкының дини тормышы өчен җаваплылык хәзер аның берүзенә йөкләнгән. Хисапны аннан гына сорарлар. Ә ул хисапны Аллаһы Тәгалә каршында тотасы бит...

Менә шулай, көтмәгәндә, Гарәпша мулла булды да куйды. Беренче эш итеп ул, өенә кайткач та, тәһарәт алып, каршыларындагы Изгеләр зиратына чыгып, озын-озаклап дога укыды, Аллаһыдан бу олы эшендә ярдәм сорады. Шуннан соң гына бераз күңеленә тынычлык, үз-үзенә ышаныч инде сыман.

Өйгә кергәч тә, карчыгы Шәмсекамәрнең аны чәй кайнатып көтүен күрде. Тәрәзәдән күзләгәндер.

– Бигрәк озаклап укыдың бүген, зираттагысы да җитеп торыр иде, – диде ул, карты турында борчылуын яшермичә.

– Менә син дә абыстай булдың, карчык, – диде тегесе.

– Ниткән абыстай тагын?!

– Мине авыл мулласы итеп билгеләделәр...

Карчыгы, теге вакытта сугыштан кайткан чагындагы төсле, лып итеп сандык өстенә утырды да балавыз сыгып җибәрде. Аннан, бераз тынычлангач, борынын мышык-мышык тарткалап, тезеп китте:

– Иии, сөбханалла, шушы көннәрне дә күрергә насыйп булган икән, син дә табын түрләренә утырып вәгазьләр сөйләрлек, җәмәгать каршында кычкырып Ясин укырлык кеше дәрәҗәсенә җиттең бит, Гарәпшам җаным!

Дәвамы бар >

Сүрия МИНГАТИНА

ГОМЕРЕМ КЕЛӘМЕ

Бизәкләп чигелә гомерем келәме –
Төсләре бик ачык, күренми карасы.
Келәмем өстеннән бәхетле елмаеп,
Килә шул туктамый гел алга барасы.

Язмышым – чигүче! Кулында – энәсе.
Остарган бармаклар җай гына
селкенә.
Җепләрен аралап бирәсем килсә дә,
Ул алган барын да үзенең иркенә.

Күзәтәм тын алмый нәкышле бизәген.
Кабатлап күчерми беркемнән үрнәген.
Сискәнеп куямын кадалса тәнемә,
Авырдан кичерәм ялгышын энәнең.

Яшьләрем чыгарга атлыга күземнән,
Рәнҗүме, үпкәләп елаумы, кем белгән.
Йөрәккә чәнчелгән урыны гел әрни,
Тәндәге яралар авырдан төзәлгән.

Инәлеп тезләнәм кайвакыт каршыңа,
Рәхмәтем – үткәнгә гомернең
яртысын.
Чуалса, өзәргә ашыкма җепләрен,
Уңайла, үтенәм,
тартылса тартылсын!

ИҢ МАТУР ТЕЛ!

Без, үскәндә, «чеп-чи» татар идек!
Югалмадык тагын үзебез.
Урысчасын ипи-тозлык кына
«Пупалаган» буын идек без.

Урыс телен авыр үзләштердек,
Карурмандай иде ул элек.
Аңламаган сүзнең татарчасы
Гел тактада торды эленеп.

Хыяллар да туган телдә иде,
Татарчадан читкә чыкмады.
Тик шәһәрдә шул урысча белмәү –
Җәлләмәде безне, тукмады.

Трамвайга керсәң, сәер караш...
Истә әле күңел тулганы.
Башка милләт көлми, безнең татар,
Читкә китеп «кеше» булганы.

Сынау биргән чакта, билет алгач,
Тәрҗемәсен уйлап тилмердек.
Белгәнеңне әйтә алмый тору
Күпкә авырлыгын без белдек.

Яраклаштык үзе. Ияләштек.
Укып чыктык, үсте балалар.
Татар мәктәбенә бирмәс өчен,
Бик тырышты ата-аналар.

«Урысча бел! Кая төртелсәң дә,
Шул тел кирәк, ансыз бик кыен.
Татарчасын син беләсең инде,
Әрәм була, балам, укуың!»

Менә җитте вакыт! Безнең буын
Оныкларын инде үстерә.
Һәр сорауга җавап эзләгәндә,
Тормышыннан мисал китерә.

Үз телебез кирәк! Бездән башка
Ялгышларны кемнәр төзәтер?
Телен белми үскән оныкларны
Кем генә соң кабат өйрәтер?

Татар теле бит ул! Әнкәм теле!
Алыштырмый аны берни дә!
Дөрес яшәдек, дип уйлый идем,
Ризасызлык әле күңелдә.

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышлана

БЕЗНЕҢ АВЫЛ ИМАМЫ

«Ватаным Татарстан» газетасы, Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте белән берлектә, «Безнең авыл имамы» дигән бәйге игълан итә.

Соңгы елларда авылларда дини тормыш игътибар үзәгендә. Бу аңлашыла да, авыл – милли һәм рухи тормышыбызның чыганагы. Авылдагы рух тотрыклыгы, хәтта татар теле язмышы да имамнарга барып тоташа.

Үзегез яшәгән җирлектәге имамнар, аларның күркәм хезмәтләре турында «Ватаным Татарстан» газетасына «бәйге» дигән тамга белән язмалар юллый аласыз.

Бәйгедә өч урын билгеләнәчәк. Аларны бүләкләү түбәндәгечә:

I урын – 10 мең сум;
II урын – 7 мең сум;
III урын – 5 әр мең сум күләмендә ике премия.

Бер җиңүчегә Татарстан Диния нәзарәтеннән 10 мең сум күләмендә махсус премия тапшырылачак.

Бәйгенең төп иганәчесе – Яшел Үзән районының Бакырчы авылыннан Бәхтияровлар гаиләсе. Игелекле эшләре белән авылдашларының, якташларының хөрмәтен яулаган бертуган эшмәкәрләр Рафыйк һәм Рәшит Бәхтияровларның эшләрен дәвам итеп, аларның якты истәлеге хөрмәтенә туганнары әлеге игелекле эшкә алындылар. Исегезгә төшереп китәбез: 2021 елда «Ватаным Татарстан» газетасы үткәргән «Шәфкать» бәйгесенең дә төп иганәчесе Бәхтияровлар булдылар.

БӘЙГЕНЕҢ ШАРТЛАРЫ:

«Безнең авыл имамы» бәйгесенә язмалар 2022 елның 4 мартыннан 2022 елның 10 июленә кадәр кабул ителә. Нигезләмә белән **www.vatantat.ru** сайтында танышырга мөмкин.

Бәйгегә башка матбугат чараларында басылган язмалар кабул ителми. Язма күләме басма форматта 3 биттән (юл арасы 1,5 интервал) артмаска тиеш.

Материаллар 420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт адресы буенча яки **konkurs_vt@mail.ru** электрон почтасына кабул ителә һәм кире кайтарылмый. Хатта авторның исем-фамилиясе, яше, торган урыны күрсәтелергә тиеш. **Белешмә өчен телефон: (843) 222 09 70, 8917 927 00 40.** Бәйгедә катнашучының 2022 елның икенче яртыеллыгына «Ватаным Татарстан» газетасына язылган булуы шарт, квитанция күчермәсе редакциягә язма белән җибәрелә. (Исегезгә төшерәбез: һәр айның 15 нче числосына кадәр язылган очракта газета киләсе айдан килә башлый.)

Бәйгенең нигезләмәсе, тулырак мәгълүмат www.vatantat.ru сайтында.
2022 елның 4 мартыннан 2022 елның 1 августына кадәр дәвам итә.
Оештыручысы – «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе, Реклама, 16+



25 февраль санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: Гопак, ызан, йомыш, рәте, аноа, чех, Абеба, кам, Лев, гәүдә, Бараба, Тан, Антон, мая, авар, Бохара, Лача, шаланда, кукуруз.
Вертикаль буенча: Маршак, Наласа, обер, ябалак, Гыймаева, оча, бархан, Гай, чаган, алдау, Оноре, тар, Мәхмүтова, Ашыт, Адана, шепкән.

Викторина

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч вариантнан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерә аласыз.

1 Бу елны Габдрахман Ильяси пьеса яза һәм ул өй шартларында куела.
А) 1812 ел;
Б) 1990 ел;
В) 1887 ел.

2 Олимпия чемпионы Гөлнара Сәмитова-Галкина Татарстанның кайсы шәһәреннән?
А) Әлмәт;
Б) Чаллы;
В) Татарстаннан түгел.

3 Вотяклар дип элек кайсы халыкны атаганнар?
А) удмурт;
Б) мордва;
В) мари.

4 Ядегәр-Мөхәммәд ханның, Мәскәүгә озатып, чукындырылгач алган исеме.
А) Семеон;
Б) Иван;
В) Феодор.

5 «Син сорама миннән, сорама, – «Яшәргә, дип, каян ут алдың?» – Ярсу елгалардан, горур кыялардан, Яшәүнең үзеннән көч алдым».
Бу шигырьнең авторы кем?
А) Гөлшат Зәйнашева;
Б) Халисә Ширмән;
В) Шәмсия Җиһангирова.

Җаваплар: 1) В; 2) Б; 3) А; 4) А; 5) В.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 17132 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 231

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+